ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

XII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумында 1100 имам катнашты

> 2

«ДИАМОБИЛЬ» ТИКШЕРӘ

Татарстанда «Шикәр чире атналыгы» бара

> 3

ГАМЬЛЕ ГОМЕР

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга – 75 яшь

> 5

БЕЗНЕҢ КИЛӘЧӘК

11 нче сыйныф укучылары арасында татар теленнән сынауны бер генә укучы сайлаган

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 70 (28843) | Шимбә | 21 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕНӘ НИГЕЗ ТАШЫ САЛЫНДЫ

tatarstan.ru

Изге көндә – изге эш. Татарстан башкаласында 10 мең кешегә исәпләнгән Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салынды. Казан халкы өчен генә түгел, мөселман дөньясы өчен тарихи вакыйга. Бу тарихны барыбыз бергә язу аерым игътибарга лаек.

Тантаналы чарада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов шулай дип белдерде.

– Бүген безнең өчен әһәмиятле вакыйга булды. Башкалабыздагы Җәмигъ мәчете төзеләчәк урынга нигез ташы салынды. Тарихыбызда мәчет төзелеше татар халкы тормышын үзгәрткән берничә мисал бар. 1767 елда Екатерина II Казанда таш мәчет төзергә рөхсәт бирә. Бүген әлеге борынгы мәчет күренекле татар әһеле Шиһабетдин Мәрҗани исемен йөртә. 1990 нчы елларда Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев башлангычы белән Кремльдә Кол Шәриф мәчете төзелешенә старт бирелде. Хәзер ул – шәһәребезнең күренекле урыннарының берсе, – диде ул. – Бу һәм башка мәчетләр җәмәгатьчелек ярдәме белән төзелү аерым игътибарга лаек. Җәмигъ мәчете дә искәрмә булмаячак. Акча җыю белән «Игелек» фонды шөгыльләнәчәк. Милләттәшләребезне, битараф булмаганнарны Җәмигъ мәчете төзелешендә актив катнашырга өндим.

Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салу Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү кысасында узды. Россия Хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин 11 гасыр элек кабул ителгән карарны тарихи дип атады.

– 922 елда бабаларыбыз, ислам динен кабул итеп, тарихи карар кылды. Бу аларның мәдәни, икътисади, сәяси үсешенә бары уңай йогынты ясады. Россия Президенты Владимир Путинның да, Россия мөселманнарының ата-бабалары традицияләренә һәрвакыт хөрмәт белән караулары, «ватанпәрвәрлек» һәм «гаделлек» төшенчәләренә тугрылык саклаулары турында берничә тапкыр әйткәне булды. Быел Президент фәрманы белән исламны кабул итүнең 1100 еллыгын федераль дәрәҗәдә билгеләп үтәбез. Шушы истәлекле дата хөрмәтенә 10 мең кешегә исәпләнгән яңа Җәмигъ мәчете төзеләчәк. Бүген без мәчетнең төзелешенә нигез ташын салабыз, – диде ул, тантанада катнашучыларга сәламәтлек һәм тынычлык теләп.

Тантаналы чарада шулай ук Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев, республиканың Премьер-министры Алексей Песошин, Чувашия, Мордовия, Карачай-Черкес, Кабарда-Балкар республикалары башлыклары, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин, Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил Гайнетдин, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башкалар катнашты.

– Бу мәчет халкыбыз, милләтебез, илебез белән бергә төзеләчәк. Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.): «Җир йөзендә Аллаһка сәҗдә кылу, Аллаһның хак динендә тәрбияләү өчен гыйбадәт урынын – мәчетне кем төзесә, шуңа Аллаһы Тәгалә җәннәтендә урын әзерли», – дигән. Татарстанда инде беренче мәчетне генә төземибез. Гыйбадәт урыннары артканнан-арта. Киләчәктә дә халкыбызның иманын ныгыту, иман нурын тагын да арттыру өчен айлары балкып торган мәчетләрне төзергә язсын. Балаларыбызга, оныкларыбызга шушы мәчетләргә гыйбадәткә килергә насыйп булсын, – диде Равил Гайнетдин.

Нигез ташы салынганчы, мәчет булачак урында ике меңләп кеше Камил хәзрәт Сәмигуллин белән өйлә намазы укыды, Коръән вәгазьләре тыңлады. Араларында Россиянең 72 төбәгеннән, 5 чит илдән килгән XII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы катнашучылары да бар иде.

Мәскәүдә гомер итүче Муратовлар әлеге тарихи вакыйганы күрергә гаиләләре белән килгән. «Безнең Россия ислам институтына укырга килгән чагыбыз белән Җәмигъ мәчетенә нигез ташы салу бер вакытка туры килде. Билгеле, мондый мөмкинлектән файдаланмый кала алмадык. Кечкенә булсалар да, ике кызыбызны да алып килдек бирегә. Изге җирдә намаз укып, мондый чараның шаһиты булуыбызга бик сөенәбез, Аллага шөкер. Мәскәүдә яшәсәк тә, ирем дә, үзем дә – Татарстанныкылар. Тарихи Ватаныбыз өчен горурлык хисе кичерәбез», – дип сөйләде безгә Руфинә Муратова.

Тарихчы Дамир Исхаков фикеренчә, без халыкның намазны урамда укуына юл куя алмыйбыз, шуңа да 10 мең кешене сыйдыра ала торган мәчетнең кирәклеге – бәхәссез мәсьәлә. «Без Мәскәүдәге хәлгә кала алмыйбыз. Казанда татарларның да, башка милләттән булган мөселманнарның да артуы күзәтелә. Мәчетләрдә урын җитмәгән вакытлар була. Мондый мәчет безгә һичшиксез кирәк. Аның урыны да уңышлы сайланган. Беренчедән, монда бик матур. Архитектура ягыннан караганда да, мәчет уртак комплекска керәчәк. Транспорт ягыннан да уңайлы. Бердәнбер мәсьәлә – мәчетнең исеме турында бәхәсләр тынмый. Миңа калса, бу мәчетнең исеме «Нур-Али» булырга тиеш. XVI гасырда «Нур-Али» мәчете булган. Мәчет ул чакта Хөкүмәт башында торган Нургали исемле кенәз хөрмәтенә аталган. Бу исем тарихи әһәмияткә ия», – дип сөйләде ул безгә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ТАРИХИ БӘЙРӘМ



Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы МИҢНЕХАНОВның Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителгән көнне бәйрәм итү уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле татарстанлылар!
Хөрмәтле республикабыз кунаклары!
Кадерле ватандашлар!

Сезне олы тарихи бәйрәм – Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан ихлас котлыйм.

Алмыш илтәбәр җитәкчелегендәге борынгы бабаларыбыз 922 елда бай тарихлы Болгар җирендә мәртәбәле кунаклар – Багдад хәлифе әл-Моктәдир илчелеге катнашкан зур җыенда исламны дәүләт дине буларак кабул иткәнгә унбер гасыр узган. Көнбатыш һәм Көнчыгыш традицияләре бергә үрелгән күпмилләтле Россия цивилизациясенә бәрәкәтле йогынты ясаган бу мөһим вакыйга гаять киң Идел-Урал төбәгенең киләчәктәге үсеш юлларын билгеләде.

Аллаһы Тәгаләдән үзенең пәйгамбәре Мөхәммәд (с.г.в.) аша иңдерелгән мөкатдәс ислам дине мөселман дөньясының төньяк чикләрендә ныгып урнашты, татар халкының теленә, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә, көндәлек тормышына тирәнтен үтеп керде. Раббыга чиксез рәхмәт хисләре тулы йөрәкләрендә динебезнең нурын гасырлар һәм чорлар аша саклап килгән изге ата-бабаларыбыз туган җиргә ихлас мәхәббәтне, какшамас дини-әхлакый хәзинәләрне, рухи һәм матди мәдәниятебезнең иң күркәм үрнәкләрен безгә мирас итеп калдырды.

Без хәзерге көндә рухыбызны ныгытырга, тарихи гаделлекне кайтарырга, төрле милләт һәм дин вәкилләренең дус-тату яшәү кагыйдәләренә, иҗади алгарыш, үзара аңлашу һәм шәфкатьлелек идеалларына нигезләнеп яшәргә омтылабыз. Торгызылган Борынгы Болгарда һәм Татарстанның күпсанлы мәчетләрендә элеккеге заманнардагы кебек үк моңлы азан яңгырый, Болгар ислам академиясендә, Россия ислам институтында, мәдрәсәләрдә мөселман дин гыйлеменең үсеше күзәтелә.

Шунысы куанычлы: Россия Федерациясе Президенты В.В. Путинның һәм мөселманнарның үзәкләштерелгән дини оешмаларының ярдәме нәтиҗәсендә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы федераль дәрәҗәдә билгеләп үтелә. Бу уңайдан бөтен Россия һәм республика күләмендә бик күп чаралар, фәнни һәм мәдәни форумнар уздыру, мәшһүр дин галимнәренең хезмәтләрен бастырып чыгару, ислам белән бәйле хуҗалык даирәсен киңәйтү һәм башка шундый эшләр каралган. «KazanSummit» халыкара икътисади саммиты, «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең пленар утырышы, Татар дин әһелләренең «Милли үзенчәлек һәм дин» XII бөтенроссия форумы, «Изге Болгар җыены» һәм Казандагы Җәмигъ мәчетенең беренче нигез ташын салу тантаналары иң күренекле вакыйгалар булачак.

Болар һәммәсе дә – дини һәм рухи яңарышның, буыннар арасындагы мәдәни-тарихи, милләтара һәм динара бәйләнешләр ныгуының, дини оешмалар белән дәүләт арасында урнашкан нәтиҗәле хезмәттәшлекнең ачык дәлиле. Бәйрәм көннәрендә һәркем динебез тарихының башлангыч чоры белән якыннан танышу, узган дәверләрдә халыклар язмышында борылыш китереп чыгарган вакыйгалар белән бәйләнешен тою мөмкинлегенә ия булачак.

Кадерле дуслар, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын күтәренке рух белән бәйрәм итүегезне телим. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә бәхет, тынычлык, игелек һәм иминлек насыйп итсен, үзебезне һәм күпмилләтле Ватаныбызны рәхим-шәфкатеннән ташламасын!

Хезмәттәшлек

Бергә җиңелрәк

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ ИЛЛӘРЕ РОССИЯДӘН ЙӨЗ ЧӨЕРМИ

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгы, Россия тәҗрибәсен өйрәнү, халыкара сәяси мәйданда барган вазгыятькә җавап бирү. Казанда узган «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме пленар утырышының көн тәртибе шактый җитди мәсьәләләрне барлауга багышланды.

Оештыручыларны да, катнашучыларны да сөендергән нәрсә бер булгандыр: күп юнәлешләрдә уй-фикерләр уртак икән.

Тотрыксызлык чоры

Утырыш темасы быел тарихи датага багышланган булуы белән генә түгел, әһәмиятле темага узуы белән дә башкаларыннан аерылып тора. Бу юлы Россиянең этномәдәни күптөрлелек, милләт һәм динара татулыкны саклаудагы тәҗрибәсе турында сөйләштеләр. Чарада дөньякүләм һәм федераль дәрәҗәдәге сәясәт, бизнес, иҗтимагый тормыш, мәдәният вәкилләре, дин әһелләре катнашты.

Билгеле, чикләү шартларында хезмәттәшлеккә әзер һәм сәләтле партнерлар эзләү бурычы килеп баса. Бу җәһәттән «Россия – Ислам дөньясы» мәйданчыгы шул бурыч үтәлүгә мөмкинлек бирә торган очрашу урынына да әверелде.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, стратегик караш төркеменең максаты – дөнья җәмәгатьчелегенә Россиянең дини юнәлештәге, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләргә бәйле уңай тәҗрибәсен күрсәтү.

– Очрашуыбызның көн тәртибе итеп сайлаган темабыз төркемнең бурычларына, шулай ук милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр өлкәсендә барган катлаулы мәсьәләләргә бәйле, – диде ул. – Тема дөньяның барлык дәүләтләргә дә кагыла торган куркыныч тотрыксызлык чорына керүе сәбәпле дә актуаль. Халыкара институтлар һәм мөнәсәбәтләр системасы җимерелә, хокукый үзгәрешләр бара. Террористик һәм экстремистик оешмалар саны арта, неонацизмның яңадан торгызылуы һәм үсешенең куркыныч тенденциясе күзәтелә. Россиягә карата моңа кадәр күрелмәгән санкцияләр кулланыла. Без мөселман һәм гарәп дөньясының күпчелек илләренә шушы басымга бирешмичә, элеккечә үк безнең ил белән хезмәттәшлекне үстерүләре өчен рәхмәтле.

Рөстәм Миңнеханов Көнбатыш илләрен ялган фикерләр таратуда да гаепләде. «Россия турында күпләп ялган хәбәрләр таратырга тырышалар. Әмма берни дә барып чыкмый. Бар дөнья күпмилләтле Россиянең бердәмлеген күрде. Мондый берләшү Бөек Ватан сугышы елларында күзәтелгән. Бу вакытта безнең ил фашизм белән көрәшкән. Зур илебезнең көче – бердәмлектә», – диде Татарстан Президенты.

Фикерләшү урыны

Утырыш кунаклары арасында Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин да бар иде. Ул дәүләт башлыгы Владимир Путинның тәбрикләү сүзләрен җиткерде, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеменең әһәмияте турында фикерләре белән уртаклашты.

– Төркем эшчәнлеге үзенең нәтиҗәлелеген исбатлады һәм халыкара мөнәсәбәтләр мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен әһәмиятле мәйданчык булып танылды, – диде Марат Хөснуллин.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Камил СӘМИГУЛЛИН, Татарстан мөфтие:

Россиядә ислам дине тарихына күз салсак, ислам дине әһелләренең гомер-гомергә халыклар бердәмлеген һәм рухи кыйммәтләрне саклау мәсьәләсендә мөһим роль уйнап килүен күрергә мөмкин. Дин әһелләре гаять катлаулы сәяси вазгыять шартларында да кешеләрне туплау, аларны илһамландыру һәм дөрес юлга бастыру буенча чиктән тыш зур сәләткә ия булуларын күрсәтте.

(«Татарстан» журналы)

РОССИЯДӘ – СПОРТ

«Rambler&Co» медиахолдингы Россиядә яшәүчеләрдән спортка мөнәсәбәтләре турында сорашкан.

ИҢ ПОПУЛЯР СПОРТ ТӨРЛӘРЕ

Йөгерү һәм спорт йөреше	40%
Велосипедта йөрү	14%
Спорт мәйданчыкларында шөгыльләнү	10%
Футбол	9%
Теннис һәм бадминтон	8%

ЕШ ШӨГЫЛЬЛӘНӘСЕЗМЕ?

Атнасына 3 тапкыр, урамда	26%
Даими күнекмәләр, саф һавада	34%

«Казан басмасы» интернетка чыкты

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте яңартылган «Казан басмасы»ның электрон нөсхәсен һәм компьютер шрифтын гомумкулланышка тапшырды. Аны нәзарәт сайтыннан бушлай алырга мөмкин.

Белгечләр «Казан басмасы»ның тарихи типографик эзеннән (оттискыннан) шул ук исемдәге компьютер шрифты ясаган, аннары Коръән текстын «Казан басмасы» компьютер шрифты ярдәмендә яңадан җыйган. Эш барышында күренекле татар галимнәре Шиһабетдин Мәрҗани, Муса Бигиевның искәрмәләре дә исәпкә алынган.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

Төрлелек белән затлы без

Иртәгә Биологик күптөрлелек көне. Бу сүз нәрсәне аңлата? Җирдәге һәр үсемлек, һәр агач, һәр җан иясе, кырмыскадан башлап филгә кадәр, моңарчы бик күп еллар ничек яшәгән, тереклек иткән булса, моннан соң да гомерле булырга, җирдә калырга тиешлекне.

...Кайсы якка гына карасаң да, чиге күренмәгән комташлы чүлне күргәнегез бармы сезнең? Ярымчүл дип аталган табигый зонаны күрергә генә түгел, анда яшәргә дә туры килде заманында. Шыксыз табигатьле, үтә ярлы флора белән фауналы, яме, хозуры булмаган тарафлар. Анда-санда үскән чәнечкеле тәбәнәк куаклар, үлән дисәң хәтере калырлык, кызу чүл җиленә баш июче берән-сәрән үскән тонык яшел үләннәр. Озак йөрсәң, каршыңнан берәр кәлтә чабып үтәргә мөмкин. Ташны тибеп җибәрсәң, астыннан сигез аягын да берьюлы кыймылдатып, койрыгын өскә күтәреп, сары чаян килеп чыга кайчак. Кошлар, имезүче хайваннар бөтенләй күренми.

Бар тарафларда шундый ярлылык, Ай ландшафтына охшаш шундый шыксызлык булса нишләр идек? Ә бит хәлләр акрынлап шуңа таба бара. Язуларына караганда, чүлләр мәйданы ел саен якынча 12000 квадрат мильгә зурая. Бу хәлне 90 процент очракта саны сигез миллиардка җиткән кыбырсык җан иясе – кешенең табигатькә кирәгеннән артык тыкшынуы белән аңлаталар. Аңлаталар, беләләр, ләкин...

Без – җирдә яшәүче ике аяклы, ике куллы кавем, үзебез, үз мәнфәгатьләребез турында гына кайгырту дигәндә, артык мавыгып киттек. Үткән дәверләрдән аермалы буларак, кеше хәзер куәтле техниканы, фәнне иярләгән. Ул коточкыч көчкә ия. Яхшыны тудыручы гына түгел, юкка чыгаручы җимергеч көчкә дә ия ул. Төп бәла шунда: үз әйләнә-тирәсен, табигатьне үзгәрткәндә, кеше андагы флора, фауна белән артык исәпләшми. Күп очракта аның гамәлләре булачак, керәчәк табышка буйсына. Табыш аның күзен томалый, сансызлыкка этәрә. Ә ахыры... Кешенең җирдәге уйланылмаган эшчәнлеге аркасында, дистәләгән, йөзләгән төр үсемлек һәм хайван бетү, югалу чигенә килеп җитте генә түгел, бик күбесе инде югалды, бетте дә. Без аларны, мәсәлән, сумкалы бүрене, атка охшаш тарпан дигән хайванны, зебрага тартым кваггины, башкаларны хәзер рәсемнәрдә генә күрәбез. Алар тереклек иткән тирәлекне, холык-фигыльләрен, ни белән туенганнарын аларны сурәтләп язган аз санлы күзәтүләр аша гына беләбез.

Югалып баручы төрләрне саклау уе җәмгыятебездә, ни гаҗәп, үткән гасыр урталарында гына туа. Беренче халыкара Кызыл китап тагын да соңрак – 1963 елда гына басыла. Ул чагында аңа 211 имезүче хайван, 312 кош кертелгән була. Үсемлекләр, бөҗәкләр, балык, рептилияләр бөтенләй булмый. Соңрак чыгарылган редакцияләрдә җан ияләренең соңгы икесе урын алса да, кайбер төрләр ул арада инде югалырга да өлгерә. Чөнки 1962 елдан соң узган 60 ел эчендә дә күптөрлелеккә һөҗүм туктамады. Экология яхшырмый. Табигатьне кысрыклау дәвам итә. Ашлама, пестицидлар күбрәк кулланыла, автомобильләр, заводлар чыгарган углекислый газның күләме арта, урманнарны кисү тизләнә. Бу үзгәрешләр үсемлекләрдән башлап зур имезүче хайваннарга, һәммә тереклеккә, беренчедән, яшәү ареалын киметсә, икенчедән, шул ук пестицидлар иртәме-соңмы бөҗәкләрне генә түгел, аларны ашаучы кошларны, эрерәк хайваннарны да эзләп таба, агулый, төрләр санын киметүгә өлешен кертеп тора...

Планетада бер генә үсемлекнең дә, бөҗәкнең, кошның, хайванның да артык түгеллеген исбатлап тору кирәк микән? Миллион, миллиард ел буе барган эволюция нәтиҗәсендә аларның һәрберсе табигатьтә, биосферада үз кыштәсен, урынын тапкан. Ул гына да түгел, әйләнә-тирә мохиткә зарар салучы бер генә үсемлек тә, хайван да юк. Кеше үз эшчәнлеген кирәгеннән артык җәелдергәнче, алар барысы да табигый балансда, тигезлектә (равновесие) яшәгән, кайгы күрмәгән. Бүген, искәртүебезчә, биологик төрләрнең хәтсезе – яшәү белән үлем арасында. Андыйлар халыкара Кызыл китапта гына түгел, күп илләрнең үз Кызыл китапларына да кертелгән. Проблеманы аңлау яхшы, әлбәттә. Тик ул гына үсемлекләргә, җан ияләренә исәнлек гарантиясе була алмый. Җирдә кеше саны арта, аларның һәрберсенең ашыйсы килә. Интенсив агротехника, агрохимия, басулар мәйданы арту барыннан да бигрәк шуның белән аңлатыла. Адәми затның әле ашыйсы гына түгел, комфортта яшисе, автомобильдә чабасы да килә. Автотранспорт чыгарган углекислотага, аның нәтиҗәсе булган парник эффекты, температура күтәрелүгә үсемлекләр, бөҗәкләр сизгер. Аеруча сизгерләре бик тиз зәгыйфьләнә башлый, бераздан юкка да чыга. Халыкара Кызыл китапның гамәлдәгесенә 226 төр имезүче хайван, 181 кош, сөйрәлүчеләрнең 77 төре, 35 амфибия, 169 исемдәге балык кергәнлеген язалар. Ә бөҗәкләр буенча мәгълүмат юк.

Халыкара китапта, әйтүләренчә, теге яки бу илнең Кызыл китабына кергән тереклек ияләре булмаска да мөмкин икән. Әгәр дә аерым илдә югалам, бетәм дип торган җан ияләре кайгыртыла, аларны күбәйтү буенча эш алып барыла икән, әлбәттә, барлык төрне дә гомуми исемлеккә кертмәсәң дә буладыр. Ләкин андый эш белән бар дәүләтләр дә шөгыльләнми, шуңа халыкара оешмалар, халыкара Кызыл китап та бик кирәк. Тагын шунысы игътибарга лаек: Җир йөзендә, мәсәлән, йомранның исән булуы гына түгел, аның барлык төрләренең (подвиды) дә яшәве кирәк. Далада яшәгәне дә, ярымчүлдә җан асраганы да, Европадагысы да исән булырга хаклы, Африкадагысы да.

Шунысын да искәртик: имезүче хайваннарның, кошларның кайбер төрләрен, тиешле шартлар тудырып үрчеткәннән соң, Кызыл китаптан чыгару очраклары да бар. Мәсәлән, дала кошы дүдәккә (дрофа) хәзер юкка чыгу янамый. Пржевальский атының да саны торгызылган. Бу эштә, әлбәттә инде, табигый тыюлыкларның роле зур. Тик Кызыл китаптан чыгу бәхете менә-менә югалам дип торган җан ияләренең нибары 3–5 процентына гына тәти икән шул...

Дөнья күптөрлелеге белән матур һәм затлы. Гел бертөрле агачлардан гына торган урман матур була алмый. Өй салсаң да яхшы, тактага да әйбәт, шәп эшкәртелә, дип наратны гына калдырып, чаган белән тирәкне, файдага ярамау сылтавы белән бөтенләй юк итсәң, дөнья ярлылана. Болын тоташ гөлчәчәкләрдән генә торса да, башта гына ямьле күренә. Һәр болын андагы аллы-гөллелек белән, күптөрлелек белән күркәм. Һәр үләннең, чәчәкнең, агачның, хәтта суалчаннарның да җирдә үз урыны бар. Алар тагын йөз, мең елдан соң да исән булсын, яшәсен иде.

ТӨП КӨЧЕБЕЗ – БЕРДӘМЛЕКТӘ

XII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумында бу фикерне еш ишетергә туры килде. Форумның пленар утырышында катнашучылар да бердәмлекнең тормышыбызда, бигрәк тә бүгенге вазгыятьтә нинди зур роль уйнавын ассызыклады.

Форумга җыелган дин әһелләре пленар утырышка кадәр Җәмигъ мәчете төзеләчәк урында җомга намазында катнашты.

Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, күп еллар инде Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы Россия төбәкләреннән мөселман руханиларын берләштерә, дип билгеләп үтте.

– Ил Президенты Владимир Владимирович Путин мөселманнарның җәмгыятьтә милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуда, мәдәни күптөрлелекне саклап калуда, илебезнең өстенлекле мәнфәгатьләрен яклауда мөселманнарның лаеклы өлешен берничә тапкыр билгеләп үтте. Бүгенге форум кысасында кабул ителгән карарлар Россия дәүләтчелегенең тотрыклы үсешенә ярдәм итәр дип ышанам, – диде ул.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын дәүләт дәрәҗәсендә үткәргән өчен Россия Президенты Владимир Путинга рәхмәтен белдерде. «1100 ел элек ата-бабаларыбыз динне кабул итте. Бу – татарлар һәм Татарстан гына түгел, бөтен Россия мөселманнары бәйрәме», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Президент оештыру комитеты рәисе Марат Хөснуллинга да рәхмәтен җиткерде. «Нинди генә мәсьәләләр чыкса да, аңа мөрәҗәгать иттек, гел ярдәм булды. Аллаһы Тәгалә кодрәт бирсен, эшегез авыр. Йөзегез татарларга, Татарстанга һәрвакыт ачык булсын, – диде Президент. – Россиянең җиңел вакытлары түгел, Россия Президенты эшен хуплап, ил күләмендәге бу җыен – Президентыбызга зур ярдәм».

Россия мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин бүгенге шартларда ислам дөньясы белән эшне тизләтү өчен тиешле карарларны вакытында кабул итәргә кирәклеген искәртте.

– Бу хәләл индустрияне үстерүгә, ислам банкингы өчен хокукый шартлар булдыруга һәм икътисади хезмәттәшлекне үстерүгә кагыла, чөнки Россия өчен мөселман дөньясы әле күп елларга төп тышкы базар булып кала, – диде Равил Гайнетдин.

Равил хәзрәт озак гасырлар дәвамында исламның Россиядә «түземле» дин, хәтта куркуга дучар ителгән дин буларак кабул ителгәнен әйтте. «Шул ук вакытта ислам дөньясында безнең дин тулы рухи традиция буларак яши алмый дип саналды. Хәзер Россия мөселманнарына ихтирамлы һәм дустанә мөнәсәбәт белдерәләр», – диде ул.

Уникенче ел рәттән уздырылучы дин әһелләре форумының быелгысы Идел буе Болгарында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышлана. Символик рәвештә быел анда 1100 имам катнаша. Алар Россиянең 76 төбәгеннән һәм 7 чит илдән килде. Быелгы форумга Донецк һәм Луганск республикаларыннан да делегатлар бар. Башкалада узучы форум быел беренче тапкыр Хакасия белән Еврей автономияле округыннан да кунаклар кабул итә.

Иң өлкән делегат – Калининград өлкәсеннән 1925 елгы Хәким ага Бикеев. Иң яшь делегат – Пенза өлкәсеннән 19 яшьлек яшь имам Камил хәзрәт Юсеев.

116 кешелек иң зур делегация Башкортстаннан килгән. Башкортстанның Октябрьский шәһәреннән Галимҗан хәзрәт Зиннәтуллин форумда ел саен катнаша икән. Быелгысы үткәнебезгә күз салып, динебезнең ни дәрәҗәдә зур үсеш кичергәнен ачыкларга ярдәм итә дип саный ул.

– Сиксәненче елларда Татарстанда – 15ләп, Башкортстанда 16 мәчет булган булса, бүген ике тугандаш республикада 3 меңгә якын мәчет исәпләнә. Россия күләмендә 7,5 мең мәчет бар. Бу – искиткеч зур сан. 30 ел элек мәдрәсәләр дә бармак белән санарлык иде. Бүген алар дистәләгән. Динебез бик зур күтәрелеш кичерде, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Свердловск өлкәсеннән килгән Әнвәр хәзрәт Хәбиров тарихи юбилей кысасында узган быелгы форумны милләтебезне күтәрү бәйрәме дип атый.

– Ислам дине – балаларыбызны тәрбияләүдә төп маягыбыз. Юкса бүген йортларда телевизор белән интернет дигән ике шайтан утыра. Балаларны нәкъ менә шулар тәрбияли. Ислам дине туган телебезне дә сакларга ярдәм итә. Дин булган йортта ана теле дә саклана, – ди.

Чуашстан Республикасының Комсомол районыннан килгән Шәфигулла хәзрәт Аскаев, бүген яшьләргә дини белемне тиешле дәрәҗәдә биреп бетереп булмый, дип борчыла.

– Динебез катлаулы шартларда кабул ителгән. Аллага шөкер, менә шундый көнгә килеп җиттек. Динебезнең бүгенге торышыннан бик канәгать без. Бу белемнәрне яшьләребезгә дә җиткерергә тырышабыз. Кызганыч, авылыбыз кечкенә. Казан яшьләребезне йотып бара. Шуңа күрә бу эшне күңел теләгәнчә үк дәрәҗәдә башкарып бетереп булмый әле, – дип күрсенә хәзрәт.

Форум ахырында катнашучылар резолюция кабул итте. Анда алдагы елга максат- бурычлар билгеләнде. Максатлар исемлегендә ин зуры – Казанда Коръәннең беренче тиражын бастыруга 220 ел тулу уңаеннан, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның 2021 елның 24 ноябрендә Җиддә шәһәрендә (Согуд Гарәбстаны) бәян ителгән тәкъдимнәрен тормышка ашыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү. Монда 2023 елны Коръәннең беренче Казан басмасы елы дип игълан итү, чит илләрдәге ислам галимнәре катнашында Россиядә һәм мөселман дөньясы илләрендә Коръәнне бастыру тарихы буенча фәнни конференция үткәрү күздә тотыла.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БЕРГӘ ҖИҢЕЛРӘК

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Аның сүзләренчә, Россия дәүләтчелегенең, тарихының һәм мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булып нәкъ менә ислам дине тора. Россиядә 10 млн кеше шушы дин тарафдары санала.

Марат Хөснуллин искәртүенчә, Казандагы очрашу катлаулы чорга туры килде.

– Көнбатыш илләренең явыз йогынтысына каршы тору шартларында изге китапларда күрсәтелгән әхлак нормалары юкка чыга һәм бозыла. Без бу үзгәрешләрнең халыклар арасында таралуына шаһит булдык. Россия шуңа каршы актив көрәшә. Без ислам дәүләтләреннән килгән хезмәттәшләребезгә фикер алышулары һәм ярдәме өчен рәхмәтле, – диде вице-премьер. – Шунысы да әһәмиятле: мөселман дөньясы Россиядән йөз чөермәде. Украина территориясендә барган махсус операциягә карамастан, хезмәттәшлек җепләре өзелмәде, мөнәсәбәтләр сакланып калды.

Тагын да ныгысын

Мөнәсәбәтләрне өзү берни түгел анысы. Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин исә ислам илләрен Россия белән элемтәләрне тагын да ныгытырга чакырды.

– Россия һәм ислам дөньясы араларының якынаюы теләгән кадәр тиз бармый. Кызганыч, бу эштә каршылыклар бар, – диде ул. – Кайбер түрәләр ислам дөньясы илләренең әһәмиятен тулысынча аңлап бетерми әле. Шунысын күзәтергә мөмкин: ислам һәм мөселманнарны кичә тәнкыйтьләп утырган кешеләр бүген безнең илдә яшәргә кайта, бизнесын ача. Тиз үзгәргән сәяси вазгыять шартларында Россиядән һәм аның халкыннан ислам дөньясы баш тартмады.

Равил Гайнетдин, ил өчен мөселман дәүләтләре белән хезмәттәшлек әһәмияте турында сөйләгәндә, хәләл индустрия, ислам банкы тармагы, гомумән, икътисади юнәлешләрне телгә алды.

Сәяси вакыйгалар бер безне генә борчымый, билгеле. Киләчәкне бүгеннән кайгырта башлауның хәерлерәк икәнен утырышта катнашкан чит ил кунаклары да әйтте.

Соңрак исә Рөстәм Миңнеханов та, бу сүзләрнең буш вәгъдә булып кына калмасын дәлилләп: «Россиягә карата күп кенә илләрнең мөнәсәбәте үзгәрде. Ә гарәп дөньясы, ислам дәүләтләре – биредә. Алар безнең белән. Без исә элемтәләрне киңәйтү турында уйланабыз, булганнарын саклап калу өчен тырышачакбыз», – дип ышандырды.

Шәхес роле

Утырыш барышында күпчелек ил башлыгы Владимир Путинны искә алды. Дөресрәге, дәүләт җитәкчесенең Россиядә ислам хезмәттәшлеген ныгыту, ислам диненең әһәмиятен аңлап эш итүен искәртте. Бу фикерне Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә җиткерде.

– Үзгәртеп кору елларында Татарстан «Ислам конференциясе» оешмасы (хәзер – Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы) белән эшлекле элемтәләр урнаштырды. 2005 елда Россия әлеге оешмага күзәтүче буларак керде, шуннан соң ислам дәүләтләре белән элемтә булдырылды. Бу адым безнең ил өчен бик мөһим иде, ул безне ислам дөньясы белән мөнәсәбәтләрнең яңа дәрәҗәсенә күтәрде, – диде Минтимер Шәймиев. – Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын федераль дәрәҗәдә каршылау турында карары өчен ил җитәкчесенә рәхмәт. Бу чын мәгънәсендә дөрес адым иде. Шул ук вакытта бу – безнең күпьеллык уңышлы эшчәнлегебезнең нәтиҗәсе дә.

Сүз уңаеннан, төркемнең чираттагы утырышы 2023 елда Малайзиядә узачак. Ул Россия Президентының Куала-Лумпурга беренче сәфәре һәм «Ислам конференциясе» оешмасына керү нияте хакында белдерүенең 20 еллыгына багышланачак. Юбилей датасын шулай ук зурлап оештыру нияте бар. Россиядән – 36, чит илләрдән 33 вәкил катнашуы көтелә.

Утырышта рәхмәт сүзләрен Минтимер Шәймиев тә ишетте.

– Путинга мин рухи-әхлакый яңарышка ярдәм иткәне өчен рәхмәтле. Ә Минтимер Шәймиев – минем өчен иң кадерле һәм хөрмәтле аксакал, – диде Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең баш мөфтие Тәлгать Таҗетдин үз чыгышында, беренче Президентның милләт һәм динара мөнәсәбәтләрне ныгытуда башкарган эшләренә ишарәләп.

Сүз уңаеннан, Тәлгать Таҗетдин 1100 еллыкка бәйле бәйрәм итү чарасы бүген-иртәгә генә төгәлләнмәячәк дигән ышанычын белдерде. «Без аны кояш буенча да, ай буенча да бәйрәм итәчәкбез. Ул Кыямәт көненә кадәр дәвам итәчәк!» – диде баш мөфти.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Бәхетле киләчәк өчен

Халыкларга һәм илгә бәрәкәт китерсен. Төркия Президенты Рәҗип Тайип Әрдоган «Россия – Ислам дөньясы: KazanSummit 2022» XIII халыкара икътисади саммиты уңаеннан юллама җибәрде.

«Россия – Ислам дөньясы» халыкара икътисади саммиты уңышлы узсын һәм безнең илләргә һәм халыкларга иминлек китерсен дип Аллаһтан сорыйм. Саммит Россиядәге мөселман кардәшләребез һәм ислам дөньясы арасында гуманитар, икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәтләрне үстерүгә ярдәм итәр дип ышанам. Моннан тыш, 2022 елда Казан саммитын уздыру Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм иткән вакытка туры килүе аеруча мөһим. Кадерле кардәшем, Президент Миңнеханов аша Татарстанның тугандаш халкын һәм оештыручыларны саммитны уңышлы уздыру белән котлыйм», – диелә юлламада.

Әрдоганның хатында әйтелгәнчә, Россия һәм Татарстанда яшәүче мөселман кардәшләрне алар ил белән мөнәсәбәтләрне ныгытуда өстенлекле дип саный. «Дөньяның кайсы почмагында яшәсәк тә, йөрәкләребез, кыйблабыз, фикерләребез, азан һәм изге китабыбыз бердәм булып кала», – дигән фикердә Төркия Президенты.

«Безнең уртак территорияләрдәге күңелсез вакыйгалар халыкара системаның глобаль бурычларга җавап таба алмавын, аерым алганда, гаделсезлеккә карата кирәкле карарлар таба алмавын күрсәтә. Безнең бурыч – мәрхәмәтлелек, юмартлык, тынычлык, хокук һәм гаделлек идеяләрен саклау, диннәренә карамастан, барлык кешеләргә бертигез карау. Әгәр без моны эшли алабыз икән, безгә иртәгәге көнне тагын да яктырак һәм бәхетлерәк итүгә ирешү җиңел булачак. Ышанам: Казандагы саммит уртак киләчәк өчен яңа идеяләр тууга өлеш кертәчәк», – дигән сүзләр бар юлламада.

Элемтәләр ныгый

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республикабызга килгән кунаклар белән очрашулар үткәрде.

Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләренең яшь дипломатлары форумында катнашучылар да хөкүмәт йортында булды. Очрашуда оешмага керүче 17 дәүләт вәкиле катнашты.

«Яшь дипломатлар белән элемтәләр безнең өчен бик мөһим. Россия Тышкы эшләр министрлыгының Яшь дипломатлар советы белән берлектә чаралар үткәрү бик әйбәт традициягә әйләнде. Башлангычлар һәм проектларыбызны хуплавы өчен тышкы эшләр министры Сергей Лавровка эчкерсез рәхмәтлебез», – дип басым ясап әйтте Рөстәм Миңнеханов.

Алты ел эчендә форумда 35 илдән 160тан артыграк вәкил катнашкан. Ул «Россия – Ислам дөньясы» Стратегик фаразлау төркеме чаралары планын тормышка ашыру кысасында уза. «Ислам хезмәттәшлеге оешмасының үзәк аппараты һәм аның махсус институтлары белән мөнәсәбәтләрне югары бәялибез. Быел Казанның ислам дөньясы яшьләре башкаласына әйләнүе күңелдә канәгатьлек хисләре уята. Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын билгеләп үтүгә бәйле рәвештә аеруча зур әһәмияткә ия бу», – диде Президент.

Татарстан мөселман илләре белән төрле юнәлешләр буенча эшли. Иң элек – сәүдә-икътисади хезмәттәшлек өлкәсендә. Әмма сәүдә әйләнешен үстерү мөмкинлекләреннән тулысынча файдаланылмый әле. Бу юнәлештәге эшне көчәйтү кирәк, дигән фикердә Рөстәм Миңнеханов.

Республика җитәкчесе Бәхрәйн Ислам эшләре югары советы Рәисе, шәех Абдурахман бин Мөхәммәд бин Рәшид Әл Хәлифә җитәкчелегендә әлеге ил делегациясен дә кабул итте.

Үзара хезмәттәшлек өчен иң перспективалы юнәлешләрнең берсе – ислам финанс системасы. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Бәхрәйн Якын Көнчыгышта мөһим финанс үзәге булып тора. Татарстан, үз чиратында, Россиянең ислам банкингын гамәлгә кертү буенча пилот төбәккә әйләнде.

Рөстәм Миңнеханов Палестинаның Хеврон провинциясе губернаторы Җибрин Ильяс Абәд әл-Бакри белән дә очрашты. Очрашуда Россия – Палестина хезмәттәшлеге кысасында алга таба үзара файдалы мөнәсәбәтләрне үстерү каралды. Рөстәм Миңнеханов басым ясап әйткәнчә, 2020 елда Россия Президенты Владимир Путинның Палестина лидеры Мәхмүд Аббас белән очрашуында икътисади, шулай ук гуманитар элемтәләр өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерүгә әзерлек белдерелгән. Татарстан Президенты әйтүенчә, республика Россия белән Палестина арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгытуга ярдәм итәргә әзер. Ул, аерым алганда, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе, энергетика, машина, автомобильләр төзү өлкәсендә һ.б. элемтәләрне үстерү өчен зур мөмкинлекләр барлыгын билгеләп үтте.

Казахстанның мәдәният һәм спорт министры Дәүрән Абаев белән очрашуда мәдәният өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне алга таба ныгыту мәсьәләләре каралды. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Татарстан һәм Казахстанның тугандаш халыкларын бер дин, тел һәм мәдәниятләрнең охшашлыгы берләштерә.

НӘСЕЛЕ БАРНЫҢ ИСЕМЕ БАР

ШӘҖӘРӘ

«Ватаным Татарстан» газетасы һәм Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының уртак проекты

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан үткәрелүче «Без тарихта эзлебез» бәйгесенең Яшел Үзәндәге зона ярышларында Тәтеш районы Олы Тархан авылыннан Гыйльметдиновлар (Сибишевлар) гаиләсе дә җиңү яулады.

– Әбиебез гел, нәселе барның исеме бар, дип кабатларга ярата иде, – ди Әлфинур ханым. – Чыннан да, һәр гаилә – зур бер сандык кебек бит ул. Шуны ачып, әби-бабайлардан мирас булып калган хәзинәне эзләү, тикшеренү күңелгә үзе рәхәтлек бирә.

Әнә шул эзләнүләрнең нәтиҗәсен күрсәтә дә инде алар бәйгедә. Аш-су өлкәсендә дә сынатмыйлар, күргәзмәгә чиккән сөлгеләр, аш җәймәләре, мендәр тышлары алып килгәннәр. Шунысы сөенечле: күбесе әниләренең кул эшләре икән. Буыннан буынга истәлек булып килгән, берничә буынны тәрбияләгән бишеккә кадәр эленеп торган.

– Әби-бабайдан калган иң зур хәзинәбез – Коръән китабы, – ди Әлфинур ханым. – Бик яхшы хәтерлим әле: озын кышкы кичләрдә әбиебез янына түгәрәк ясап җыелышып утырыр идек тә, ул бик пөхтәләп, саклап кына кулына шушы изге китапны алыр иде. Шундый утырмалар бик тә кызык, истәлекле булып хәтердә калган. Без гел әби белән бабай тәрбиясендә булдык. Үзем балалар үстергәндә аларның искиткеч дөрес тәрбия биргәннәрен кайта-кайта аңладым. Шөкер, үз балаларыбыз да әби-бабай янында үсеп, дини тәрбия алдылар, намаз укырга өйрәнделәр, Коръән кушкан буенча гамәл кылырга кирәклеген белеп үстеләр. Хәзер инде шул ук юл белән үзебез оныклар үстерешәбез. Үрнәк алыр кешеләребез бар бит.

Бер караганда, мондый гаиләнең шәҗәрә бәйгесендә җиңеп чыгуы гаҗәп тә түгел кебек. Бергәләшеп гармунда да уйный әле алар (монысы да – бабайларыннан калган хәзинә), тамашачыларга күрсәткән нәсел агачының тамырлары да нык, ботаклары да тармаклы.

– Нәсел җепләрен барлау белән 2007 елда шөгыльләнә башлаган идем, – дип дәвам итә Әлфинур ханым. – Әлегә сигез буынның тарихын таба алдым. Дөрес, шәҗәрәне бабам Насыйбулла Сибишев 1920 елда ук төзи башлаган. Бәхеткә, сакланган, югалмаган. Бөтен туганнарны да җәлеп итеп, бергәләп эшләү тагын да кызыклырак һәм нәтиҗәлерәк икән. Кем дә булса ниндидер яңалыкка гел юлыгып тора. Үзебезчә әллә нинди ачышлар ясап бетердек кебек тоела. Урдяков фамилияле орынып яшәүче күршеләр туганнарыбыз булып чыкты. Шуны белгәч, шатланып туя алмадык. Өлкән яшьтәге авылдашларыбыз да хатирәләрен барладылар. Сибишевларның алты ир туганын «чичүн»нәр дип йөрткәннәр икән. Бу «чечен» сүзеннән алынган. Чөнки алар барысы да озын буйлы, көчле, матур, батыр булганнар. Әле сугышка кадәр үк авылда «Чечня сугышы» оештырганнарын хәтерлиләр. Авылдашлар әйтүенчә, абыйларым ниндидер гаделлек өчен көрәшкәннәр. Бөек Ватан сугышы башлангач та, алты туган бергә-бергә туган илне сакларга киткән. Берсе һәлак булган, бишесе күкрәк тулы бүләк белән кайткан. Әмма сугыш сугыш инде: кем кулсыз, кем күзсез калган, кайсысы контузиягә эләккән. Әмма бирешмәгәннәр, тыныч тормышта берсе дә югалып калмаган. Һәрберсе нинди дә булса һөнәр үзләштергән. Арада чүлмәк ясаучылар да, гармунчылар да бар.

Әлфинур ханым үзе Олы Тархан хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшли. Авылдашларына игелек һәм изгелек өләшә. Хәләл җефете Гыйльметдинов Ринат Азат улы да шунда ук баш табиб вазыйфасын алып бара. Бергә булгач, киңәш-табыш итәргә дә, эшләргә дә җайлы, диләр.

– Нинди генә һөнәр иясе булмасын, һәр гаиләнең үз байлыгы, үз гореф-гадәтләре бар, – ди Әлфинур ханым. – Тик алар онытылмасын, югалмасын, буыннан буынга күчә барсын иде. Бу гамәл хәтер югалмасын өчен бик кирәк.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ТАБИБЛАР ҮЗЛӘРЕ КИЛӘ

Сәламәтлек

Казан шәһәренең 7 нче хастаханәсендә «Диамобиль» проекты кысасында, шикәр чире белән авыручы 350дән артык кешенең сәламәтлеген тикшерәчәкләр. Башкалага Мәскәү табиблары килде.

Аларга күренергә теләүчеләр күп. Андыйлар өчен дә чаралар үткәрелә. Республикада «Шикәр чире атналыгы» бара. Теләгән һәр кеше тикшерү уза алачак. Бу хакта Татарстанның штаттан тыш баш эндокринологы Гөлнар Ваһапова сөйләде. Аның әйтүенчә, Татарстанда 130 мең кеше шикәр авыруы белән исәптә тора.

– Авыручыларның 120 меңендә шикәр авыруының – II, 10 меңендә I тибы ачыкланды. Бездә чир өлкәннәр арасында киң таралган. Соңгы еллардагы пандемия дә күп кенә авыруларны кузгатты. Шуңа да Мәскәү табибларына беренче чиратта ковид кичергән шикәр авырулы кешеләрне чакырдык, – ди ул.

«Диамобиль» проекты иң беренче сәяхәтен Казаннан башлаган булган инде. 20 елдан соң алар янә безгә килде. Диабет институты директоры, Россия Фәннәр академиясе академигы Марина Шестакова 20 ел элек үзләрендә тикшерену узган кешеләрне дә чакыруларын әйтте. Шул рәвешле, алар авыруларның сәламәтлеген чагыштырып карамакчы.

kazanfirst.ru

– Татарстанда авыруларга мөнәсәбәт бөтенләй икенче. Шикәр чире белән интегүчеләр турында булган мәгълүматны ачып җибәрүгә, авыруның ничәнче елдан бирле дәвалануы, башка тагын нинди авырулары барлыгы бәйнә-бәйнә язылган. Бу безнең өчен бик уңайлы, – ди Марина Шестакова. – Берничә көн эчендә тикшерелгән авырулардан чыгып шуны әйтә алам: Казан табибларының эшчәнлеге безнекеннән бер дә аерылмый. Барыбыз да дөрес юнәлештә барабыз.

«Шикәр чире» дигән диагноз куелуны кабул итә алмаучылар да бар. Балаларында да шушы чир ачыклангач, аерылышучылар да җитәрлек. Ә кайбер кеше үзендә шикәр чире икәнен бик озак еллар белми. Казанда яшәүче Галия Ибраһимова шушы чире барлыгын 45 яше тулган көнне белә.

– Бик матур киенеп, ресторанга баруым иде. Иремнән иртәрәк чыккач, участок табибына да сугылып, тапшырылган анализ нәтиҗәләрен сорамакчы булдым. Ул миндә шикәр авыруы булуын әйткәч, елап беттем. Юкса бала-чага да түгел инде! Чир турында белмәү үзенекен итте. Әле ярый ирем – сабыр кеше. Ул китаплар алып кайтып бирде. Шөкер, бер дигән итеп яшәп ятам, – ди Галия апа. – Монда чакырып китерделәр. 20 ел элек тә күренгән булганмын икән. Анализларымны начар димиләр. Киресенчә, чирнең азмаганын әйттеләр. Дөрес итеп туклансам, тыныч кына яшәсәм, кандагы шикәрем күтәрелми.

Тикшеренергә килүчеләр иртән ашамаска тиеш. Иң элек ач килеш кан анализларын алалар. Аннары инде ашаталар да канны кабат тикшерәләр. Шул арада авыруларны күз табибы, кардиолог, диабетолог карый, бөерләренә дә игътибар итәләр.

– Шушы көннәрдә Россия Президенты Владимир Путин «Шикәр чире белән көрәшү» федераль программасын булдырырга кушты, – ди Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков. – Без бу программаны пилот проект буларак үзебездә дә эшләтеп җибәрергә җыенабыз. Бүген Россиянең баш эндокринология оешмасы белән хезмәттәшлек турында килешү дә төзедек. Ковид шикәр авыруын тагын да катлауландырды. Шуңа без авыруларны дәвалауның сыйфатын тагын да арттырырга тиеш.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Казан дәүләт аграр университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе хезмәткәрләре: агробизнеста машиналар һәм җиһазлар кафедрасы доценты **Дмитриев** Андрей Владимировичка; хуҗалык эшчәнлеге һәм икътисади эшчәнлек буенча проректор **Закиров** Зөфәр Расыйх улына; гомуминженерлык дисциплиналары кафедрасы доценты **Мостафин** Әнәс Әмин улына; гомуминженерлык дисциплиналары кафедрасы мөдире **Пикмуллин** Геннадий Васильевичка; үсемлекчелек, җиләк-җимеш һәм яшелчәчелек кафедрасы профессоры **Шәйхетдинов** Фәрит Шәрип улына; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе финанс-икътисад бүлеге консультанты **Гәрәева** Ирина Ильиничнага; Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү-маркетинг бүлеге башлыгы **Гасимов** Рәис Гаян улына; «Сарман икмәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Сарман районы) **Нуруллин** Рөстәм Рифгать улына; «Сафиуллова Рима Гомәр кызы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы урынбасары (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Савельев** Евгений Алексеевичка; «Чынлы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең кырчылык бригадасы бригадиры (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Усманов** Рәмис Мөбарәкҗан улына; «Татарстанның агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең агросәнәгать комплексы продукциясе җитештерү һәм эшкәртү технологияләре кафедрасы мөдире **Фомин** Владимир Николаевичка; «Август-Мөслим» икмәк кабул итү предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Шәмсетдинов** Айрат Гайнемөхәммәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен хезмәт ветераны **Вәлиев** Тәлгать Вахит улы, **Хәйруллин** Илгизәр Хөснулла улы; хезмәт ветераны **Манюшев** Мөнир Хәйдәр улы; Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре һөнәр берлегенең Татарстан Республикасындагы төбәк оешмасы рәисе **Прохоров** Юрий Петрович; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасының комсомол ветераннары берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзалары: хезмәт ветераны **Сибагатуллина** Җәмилә Абдулла кызы; Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе методисты **Сорокина** Нина Федоровна; Казан шәһәре Совет районының «Азино» балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Сөнгатуллина** Фәридә Галәттин кызы; хезмәт ветераны **Таҗиев** Сәлахетдин Фәрди улы; Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының балаларга өстәмә белем бирү бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Федоров** Семен Петрович **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«В.Б. Шнепп исемендәге үзәктән куучы һәм роторлы компрессорлар буенча фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык институты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Ибраһимов** Евгений Рәшит улына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Казан шәһәре Вахитов районының «Балалар иҗаты үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең оештыру-масса бүлеге методисты, «Татарстан вожатыйлары» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе **Абдуллина** Эльза Альберт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасының «Чаңгы ярышлары һәм биатлон федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы спортчылары: **Гаянова** Эльмира Әсгать кызына; **Ларьков** Андрей Витальевичка; Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Барс» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе тренеры **Комендантов** Михаил Викторовичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ВТ Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлана

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

Игелекле алмагач тарихы

Чыкты, ахры, бездән дә бер бөтен кеше,
Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше;
Татарда да гыйрфан уты кабынганны
Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.

(Г.Тукай)

Габдулла Тукайның әлеге тирән мәгънәле шигырен ишетүгә, Арча станциясендәге «Изгеләр» мәчетенең имам-хатыйбы, хөрмәтле, укымышлы авылдашым, әти-әниемнең балачак дустын – Хәлим хәзрәт Кәримовны күз алдына китерәм.

Тирә-якта һөнәрчелеге – саман кирпечләре, чигүле читекләре белән дан тоткан, заманында гөрләп торган милли аяк киемнәре фабрикасы булган авыл ул минем туган авылым Кылачы!

Арча районы Кылачы авылында 1948 елның 1 гыйнварында Кәрим абый һәм Сания апа гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә Хәлим абый. Башлангыч белемне туган авылыбызда ала, аннан Урта Сәрдә мәктәбендә укый. 8 нче сыйныфны Казан шәһәре мәктәбендә тәмамлап, Казанда һөнәр училищесында белем ала. Илебез алдындагы бурычын үтәп, Калуга, Егорьевск шәһәрләрендә армия хезмәтен дә уңышлы гына үтә.

Армия хезмәтеннән соң туган авылыбызга әйләнеп кайта ул. 1929 елда «Тукай» артеле булып оешкан, 1941 елда «Труд» артеле итеп үзгәртелгән данлыклы фабрикабызга слесарь-көйләүче булып эшкә урнаша. 1972 елда фабриканы Арчага күчереп, «Арча милли аяк киемнәре фабрикасы» итеп үзгәртәләр. Кылачы авылының яртысы диярлек Арчага күченә ул вакытта. Хәлим абый авылда да, Арчада эшләгәндә дә алдынгылар рәтендә бара, министрлыкның Мактау кәгазьләренә ия була.

2000 елда үзгәртеп кору җилләре кагылып, фабрика ябыла. Тормышлар үзгәрә. Нәрсә этәргеч булгандыр, Хәлим абый үзе дә аптырый: ул үзлегеннән гарәп язуын өйрәнә башлый, Казандагы Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәнең читтән торып уку бүлеген тәмамлап, имам-хатыйп һәм гарәп теле укытучысы белгечлеге алып чыга.

Белем алуын дәвам итеп, «Мөхәммәдия» югары мөселман мәдрәсәсенең кичке бүлеген тәмамлый. Тырышлыгы, үҗәтлеге аркасында Россия ислам институтының дини тәгълимат нигезләре факультетын тәмамлап, дөньяви дипломга ия була. Җиденче дистәне тутырып килгән чорында дөньяви дипломлы бакалавр дәрәҗәсенә ирешә!

Әнием Зөлхәбирә Кәримова сөйләвенчә, Хәлим абый кечкенәдән бик ярдәмчел, тәртипле малай булып үсә. «Әниләр урак урганда, аларга без дә ияребез, чүп үләннәрне җыеп, терлекләргә ашатырга алып кайта торган идек. Шул вакытта безне дә ярдәменнән калдырмый иде», – дип искә ала ул.

Аларның йортыннан ерак түгел кечкенә генә кибет бар иде. Ничәнче еллар булгандыр, яз көне Кәрим абый (Хәлим абыйның әтисе) бакчада алмагачлар утыртып йөри икән. Кибет янындагы ирләрнең берсе: «Кәрим абый, нигә азапланасың? Кайчан алма бирә башлый әле болар?! Балаларыңа да үсеп өлгермәсләр, үзегезгә дә! Олыгайдыгыз бит инде...» – дигән.

Кәрим абый елмаеп кына куйган да: «Безгә өлгермәсә, авылдашларыбызга, аларның балаларына, күрше-күләнгә булыр. Утыртам әле», – дип җавап биргән. Андагы ирләр арасында безнең әтиебез Ясәви дә булган, ул бу вакыйганы еш кына искә төшереп, безгә сөйли торган иде.

Алар яшәгән нигез әле бүген дә исән. Дөрестән дә, бакчасындагы алмагачлар һәр язда шау чәчәк атып, авылыбызны тагын да ямьләндерәләр, көзен эре хуш исле алмаларын биреп куандыралар. Күрше-күлән дә авыз итә, балалар да, авылга килгән кунаклар да бик рәхәтләнеп сыйлана ул алмалар белән. Бу яхшылык, игелек үрнәген күреп сокланмый һич мөмкин түгел! Кәрим абыйның әйткән сүзләре еллар аша кабат-кабат яңгырый сыман, татлы сусыл алмалары рәхмәтле авылдашлар күңеленә изгелек орлыклары салуын бүген дә дәвам итә.

Хәлим абый үзе дә әти-әнисе кебек игелекле: авылыбыздан китсә дә, туган авылына гел кайтып, авылдашларының тормышы белән гел кызыксынып тора, төпле фикерләрен җиткерә.

Бу хөрмәтле авылдашым турында, аның бертуганнары Фидәлия, Рәсимә, Вәсимә апалар турында авылдашларымнан матур фикерләр ишеттем. Туган авылыбыз турында Наил абый Габдрахманов язган «Авылымның йөзек кашы – сәхтиян читекләре» дип исемләнгән китаптан да күп мәгълүмат алдым: Хәлим абыйның әнисе Сания апаның бабасы Шәрәфетдин Баязит улы патша армиясе солдаты булган, рус – төрек сугышында катнашкан. Ә ул вакытта солдатта булган кешеләрне махсус укытканнар, язу таныткан­нар, аларга белем биргәннәр. Димәк, Шәрәфетдин Баязит улы бик белемле кеше булган.

Шулай ук әтисе ягыннан Хәлим абыйның бабасы Хәбибулла Хәйрулла улы да юнкер булып хезмәт иткән: заманының бик укымышлы кешесе булган. Хәлим абый әти-әнисе ягыннан бабаларының буыннан-буынга күчкән иң күркәм сыйфатларын үзендә туплаган икән бит!

Зөлфия ХӘМИДУЛЛИНА.
Арча районы Кылачы авылы

«ИНФОРМАЦИЯ, РАСКРЫВАЕМАЯ АО «ТАТЭНЕРГО», В СООТВЕТСТВИИ СО СТАНДАРТАМИ РАСКРЫТИЯ ИНФОРМАЦИИ ОПТОВОГО И РОЗНИЧНЫХ РЫНКОВ ЭЛЕКТРОЭНЕРГИИ, УТВЕРЖДЕННЫМИ ПОСТАНОВЛЕНИЕМ ПРАВИТЕЛЬСТВА РФ ОТ 21.01.2004 № 24»

1) Годовая бухгалтерская отчетность АО «Татэнерго» за 2021 год, а также аудиторское заключение размещены в сети Интернет на сайте раскрытия информации ООО «Интерфакс-ЦРКИ»
http://www.e-disclosure.ru/portal/files.aspx?id=772&type=12
http://www.tatenergo.ru/about/soobshcheniya-raskrytii-informatsii/raskrytie-informatsii-uchastnika-ore/

2) Информация о тарифах на поставку электрической энергии с указанием решения уполномоченного органа исполнительной власти субъекта Российской Федерации об установлении тарифов и источника официального опубликования такого решения

Тарифы на поставку электрической энергии (мощности) АО «Татэнерго» на 2022 год

Наименование документа об установлении тарифов	Приказ ФАС от 13.12.2021 № 1392/21	
Источник официального опубликования решения	Официальный интернет-портал правовой информации http://pravo.gov.ru, 30.12.2021	
Станция	**Тарифная ставка на электричекую энергию, руб./МВт. ч (без НДС)**	**Тарифная ставка на мощность, руб./МВт в мес. (без НДС)**
1 полугодие 2021 года		
Казанская ТЭЦ-1 без ДПМ/НВ	1 189,65	93 223,83
Казанская ТЭЦ-1, объект № 6 (ПГУ) ДПМ НВ	989,95	х
Казанская ТЭЦ-1, объект № 7 (ПГУ) ДПМ НВ	981,61	х
Казанская ТЭЦ-2 без ДПМ/НВ	1 169,97	98 888,20
Казанская ТЭЦ-2 ПГУ (БЛ 1, 2) ДПМ НВ	864,67	х
Заинская ГРЭС	1 378,01	96 392,49
Набережночелнинская ТЭЦ	1 166,23	115 782,03
Нижнекамская ГЭС	32,27	115 337,90
2 полугодие 2021 года		
Казанская ТЭЦ-1 без ДПМ/НВ	1 189,65	98 469,23
Казанская ТЭЦ-1, объект № 6 (ПГУ) ДПМ НВ	992,52	х
Казанская ТЭЦ-1, объект № 7 (ПГУ) ДПМ НВ	1 010,46	х
Казанская ТЭЦ-2 без ДПМ/НВ	1 188,09	104 073,41
Казанская ТЭЦ-2 ПГУ (БЛ 1, 2) ДПМ НВ	908,22	х
Заинская ГРЭС	1 435,75	101 462,62
Набережночелнинская ТЭЦ	1 204,59	121 853,07
Нижнекамская ГЭС	36,54	121 876,73

3) Структура и объём затрат на производство и реализацию товаров (работ, услуг)

Фактическая структура производственной себестоимости (с учётом покупной электроэнергии и мощности на ОРЭМ) АО «Татэнерго» за 2021 год

№ п/п	Наименование затрат	% от общей суммы расходов
1	2	3
1.	Топливо	50
2.	Энергия	6
3.	Вспомогательные материалы	1
4.	Услуги производственного характера	3
5.	Оплата труда и страховые взносы	11
6.	Амортизация	10
7.	Расходы на ремонт основных средств	6
8.	Прочие расходы	9
9.	Расходы на покупку электроэнергии (мощности)	4
Расходы на производство и реализацию производимой продукции (с учётом расходов на покупку электорэнергиии мощности на ОРЭМ) по АО «Татэнерго» за 2021 год составили 42 194 103 руб.		

4) Информация о выбросах загрязняющих веществ, оказывающих негативное влияние на окружающую среду за 2021 год, и мероприятия по их сокращению на 2022 год:

№ п/п	**Экологические показатели**	**Единица измерения – тонны**	**2021**	**2022**	
			Факт по итогам года	**Наименование мероприятия по сокращению выбросов загрязняющих веществ**	**План/цель**
1	**2**	**3**	**4**	**5**	**6**
1	Объем выбросов загрязняющих веществ в атмосферу:				
	1.1 оксиды азота в пересчёте NO_2	т/год	8746,561	**Заинская ГРЭС**. Промывка поверхностей нагрева регенеративных воздухоподогревателей, энергетических паровых калориферов котлов №№ 2-12 **Набережночелнинская ТЭЦ.** – Чистка трубок ПСГ-1,2 турбин ст. № 3-8,10,11. – Чистка маслоохладителей, конденсаторов, встроенных пучков ТГ ст. №№ 1-8,10,11.	Снижение объёма выброса NOx на 6,22 т,
	1.2 диоксид серы	т/год	222,054		Снижение выбросов SO_2 на 15,84 т
	1.3 твердые вещества	т/год	15,518		Снижение выбросов сажи на 0,335 т, маз. золы на 0,043 т
	1.4 летучие органические вещества	т/год	58,521		
	1.5 оксид углерода	т/год	2 235,117		Снижение выбросов CO на 2,46 т
	1.6 углеводороды (без летучих органических соединений)	т/год	313,522		
	ИТОГО:		**11593,962***		
	*с учётом прочих газообразных и жидких веществ 2,669 т				

5) Информация о режиме использования и состоянии водных ресурсов

Основные показатели режимов работы Нижнекамского водохранилища за период с 01.01.2021 по 31.12.2021

№ п/п	Наименование гидроэлектростанции (далее – ГЭС)/рынок, на котором гидроэлектростанция осуществляет деятельность (оптовый рынок или розничные рынки)	Пропускная способность водосбросных сооружений при наивысшем проектном подпорном уровне (далее – НПУ) верхнего бьефа, который может поддерживаться в нормальных условиях эксплуатации гидротехнических сооружений (единица измерения – м/сек)	Выработка электроэнергии за отчетный период (единица измерения – тыс. кВт·ч)	Уровни водохранилищ по состоянию на отчетную дату (измеряются в метрах)		Тип, мощность генератора
				НПУ	Минимальный уровень, допустимый в условиях нормальной эксплуатации водохранилища (сокращенное название – УМО)	
1	2	3	4	5	6	7
1	Нижнекамская ГЭС	31650	1597502,732	63,3	62,7	СВ-1470/149-104У4, 91800/78000 кВА/кВт

6) Информация об инвестиционной программе

Раскрытие информации об инвестиционных программах производителей электрической энергии						
АО «Татэнерго», ул. Марселя Салимжанова, д. 1, г. Казань, Республика Татарстан, 420021 (Наименование организации с указанием местонахождения и реквизитов)						
Наименование инвестиционной программы, сроки начала и окончания реализации инвестиционной программы	Дата утверждения инвестиционной программы	Цели инвестиционной программы	Наименование органа исполнительной власти, утвердившего инвестиционную программу	Информация об использовании инвестиционных средств за отчетный период		
				Наименование мероприятия	Сведения об использовании инвестиционных средств за отчетный год (тыс. руб.)	Источник финансирования инвестиционной программы
1	2	3	4	5	6	7

Примечание: Деятельность по оказанию услуг по передаче электрической энергии, осуществляется в условиях естественной монополии и регулируется в соответствии с законодательством о естественных монополиях, Федеральным законом «Об электроэнергетике» и иными федеральными законами. АО «Татэнерго» в области электроэнергетики не является субъектом естественной монополии и не подпадает под критерии отнесения субъектов электроэнергетики к числу субъектов, инвестиционные программы которых утверждаются и контролируются уполномоченным федеральным органом исполнительной власти, органами исполнительной власти субъектов Российской Федерации (ст. 21 35-ФЗ «Об электроэнергетике). Формирование Инвестиционной программы по электроэнергии не требуется. Инвестиционная программа АО «Татэнерго» формируется в соответствии с требованиями постановления от 5 мая 2014 г. N 410 «О порядке согласования и утверждения инвестиционных программ организаций, осуществляющих регулируемые виды деятельности в сфере теплоснабжения, а также требований к составу и содержанию таких программ».

7) Информация о расходах электроэнергии на собственные и хозяйственные нужды генерирующего оборудования АО «Татэнерго» при выработке электрической и тепловой энергии (раздельно) с указанием наименования и типа станции за 2021 год.

№ п/п	Наименование, реквизиты, тип электростанции	Расход электроэнергии (единица измерения – тыс. кВт·ч)		
		на собственные нужды		на хозяйственные нужды
		на выработку электрической энергии	на выработку тепловой энергии	
1	2	3	4	5
1	Казанская ТЭЦ-1	99 646,053	42 338,407	612,011
2	Казанская ТЭЦ-2	98 988,463	60 424,117	1 302,148
3	Заинская ГРЭС	349 354,259	10 036,567	3 897,165
4	Набережночелнинская ТЭЦ	182 041,341	122 736,887	1 018,786
5	Нижнекамская ГЭС	22 934,429	-	1 212,375
		всего: 752 964,545	всего: 235 535,978	всего: 8 042,485

8) Информация об используемом топливе на электрических станциях с указанием поставщиков и характеристик топлива

Наименование электростанции	Вид используемого топлива	Удельный расход условного топлива на отпуск электроэнергии с шин, г/кВтч *	Характеристика топлива (теплотворная способность, ккал/м³, ккал/кг)	Общий расход топлива электростанции за отчетный период, тыс. м³, тонн	Информация о поставщике топлива (наименование, место нахождения)
1	2	3	4	5	6
Казанская ТЭЦ-1	Газ	233,0	8217	559 342	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9631	140	ООО «КАРАТ», г. Казань
РК «Горки» (КТЭЦ-1)	Газ		8217	59 690	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
РК «Азино» (КТЭЦ-1)	Газ		8212	112 438	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
Казанская ТЭЦ-2	Газ	239,3	8216	599 692	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9003	4	ООО «ППТК», г. Казань
	Уголь		6200	243	ООО «РуТЭК», г. Самара
РК «Савиново» (КТЭЦ-2)	Газ		8214	112 295	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
Заинская ГРЭС	Газ	368,0	8015	1 514 312	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9304	87	ООО «КАРАТ» г. Казань; АО «ТАИФ-НК» г. Нижнекамск
Набережночелнинская ТЭЦ	Газ	304,6	8174	1 358 494	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9597	4 157	ООО «КАРАТ» г. Казань; АО «ТАИФ-НК» г. Нижнекамск
Тепловая станция ЮЗЧ (КЦ БСИ НЧТЭЦ)	Газ		8177	14 311	АО «Газпром межрегионгаз Казань», г. Казань
	Мазут		9561	6	ООО «КАРАТ», г. Казань

* - в соответствии с РД 34.08.552-95 расчет удельного расхода условного топлива на отпуск электроэнергии с шин электростанции по каждому виду топлива не ведется. Информация предоставлена в соответствии с формой 6-ТП за 2021 год

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
18 май, 2022 ел, № 171/1515 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урыннарга, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, сайлау комиссиясе әгъзалары кандидатуралары буенча тәкъдимнәр кабул итү турында хәбәре

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 22, 26 һәм 29 статьяларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 11, 15 һәм 18 статьяларына таянып, хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән, Татарстан Республикасы Әлмәт районы территориаль сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кабул итү турында игълан итә.

Документлар 2022 елның 20 маеннан 3 июньгә кадәр эш көннәрендә 09.00–18.00 сәгатьләрдә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00) түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 420111, Казан ш., Батурин ур., 7б й. (Элемтәгә керү өчен телефон: 8(843) 292-84-33).

Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга кандидатура буенча тәкъдимнәр керткәндә, «Муниципаль берәмлекләрнең территориаль сайлау комиссияләрен, сайлау комиссияләрен, округ һәм участок сайлау комиссияләрен формалаштыру тәртибе турында методик рекомендацияләр хакында» 17 февраль, 2010 ел, № 192/1337-5 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

Искәрмә. Кирәкле документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (https://izbirkom.tatarstan.ru) «Сайлау комиссияләре» бүлеге «Территориаль сайлау комиссиясе составына вакантлы урынга хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән сайлау комиссиясе әгъзасы кандидатурасы буенча тәкъдимнәр кабул итү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
18 май, 2022 ел, №171/1516 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Зәй районы территориясендә оештырылган № 1474 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составы резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Зәй районы территориясендә оештырылган № 1474 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составы резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр итә. Тәкъдимнәр һәм кирәкле документлар 2022 елның 20 маеннан 3 июньгә кадәр эш көннәрендә 08.00–17.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00) кабул ителә.

Түбәндәге адрес буенча:

Территориаль сайлау комиссиясе (ТИК) атамасы	Территориаль сайлау комиссиясе адресы
Татарстан Республикасы Зәй районы ТИК	423520, Татарстан Республикасы, Зәй ш., Крупская ур., 6 й., 13 б. (код 8-85558) 3-48-32

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 29 статьясындагы 1 пунктындагы таләпләргә туры килмәүче затлар кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертү өчен кирәкле документларга ия булмаган кандидатуралар участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертелми.

Искәрмә. Участок сайлау комиссияләре резервына вакантлы урынга кандидатуралар буенча тәкъдимнәр керткәндә «Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибе турында» 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карарына таянырга кирәк.

«Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибе турында» 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе карары, шулай ук кирәкле документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (https://izbirkom.tatarstan.ru) «Сайлау комиссияләре» бүлегендәге «Участок комиссияләре составлары резервы» «2022 елда участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә кертү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

ТОРМЫШ КАНУННАРЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга – 75 яшь. Шул уңайдан «ВТ» аның һәм якыннарының хатирәләрен барлады.

Балачак, гаилә

Маһинур МӨХӘММӘТШИНА, әнисе:

Фәритнең бәләкәй генә уенчык гармуны бар иде, шунда уйнарга өйрәнәм дип мәш килде. Хәтерлим әле: аңа ике ярым – өч яшьләр тирәсе иде бугай, әтисе Казанга партия мәктәбенә укырга китәргә җыена. Фәрит ишегалдындагы букәнгә менеп баскан да гармунда уйный. Имеш, шулай әтисен озата. Шуннан соң әтисенә хат язу теләге уянды. Кечкенә бит әле, яза белми – кулын кәгазьгә куеп, карандаш белән әйләндереп алдык та, минем хат белән әтисенә җибәрдек. Хәйрулла соңыннан, улымның хатын гел пинҗәк кесәсендә йөртәм, көненә бернича тапкыр «укыйм», дип сөйләгән иде.

Шулай бервакыт Акташта яшәгәндә ипи пешерергә булдым. Оеткым бетеп киткән икән. Алып чык әле дип, улымны күршеләргә кертеп җибәрдем. Ул чыгып китте дә югалды. Урамда кыш, бик салкын, инде борчылудан башыма әллә нинди уйлар килә башлаган иде, кайтып керде бу. Орынып торган күршеләрдә генә булмау сәбәпле, бер өйдән икенчесенә кереп, оеткы эзләп киткән... Тапканчы, бөтен авылны диярлек әйләнеп чыккан. Ул әнә шулай үзенә тапшырылган эшне балачактан ук җиренә җиткереп эшләргә яратты.

Фәрит МӨХӘММӘТШИН:

Акташта (анда әтине партия линиясе буенча эшкә күчерделәр) без бердәнбер татар гаиләсе булдык. Җитмәсә, әти әллә гигиена саклау йөзеннәнме, әллә инде малайлар шулай булырга тиеш дигән үз карашыннан чыгыпмы, чәчемне кырып ала иде. Шуңа урамда да, мәктәптә дә мине «татарин» дип үртәүләре, бер караганда, гаҗәп тә түгел кебек. Дәрес бит инде, әмма андый мәгънәдә әйтүләре барыбер күңелгә тиде. Мин көч буенча да, акыл буенча да төшеп калганнардан булмадым үзе, әмма яшьтәшләрем белән уртак тел таба алмасам, авырга туры килер иде.

Рәисә бик бәләкәй иде әле, Әлфия мәктәп яшендә генә булса да, гел миңа тагылып йөрде. Мин – коймә башында, ул да шунда. Мин сугыша башлыйм, ул да кимен куймый. Икебез бергә сугышкан вакытлар да булгалады. Минем өстән әләкләргә бик яратты. Берәр олы кеше күренсә, абый, әни, Фәрит менә ни эшләде, дип мыжылдарга тотына иде. Әммә барып чыккан әләкчегә әйләнмәде ул. Без сеңлем белән ул вакытта да агылый белән тагылый кебек идек, хәзер дә һәр очрашуга шатланып яшибез.

Ул чордагы райком хезмәткәренең язмышы – юллар. Җимерек, үтеп булмаслык, чокырлы-чакырлы юллар. Әти гел озакка чыгып китә иде. Еракташы колхозда булмаса, берәр җиреннән соңга кадәр утырырга туры килә. Сәгать тугызда да иртә кайткан булмады. Бу аның җирендә караңгы төн дигән сүз бит инде. Шуңа карамастан, әти гаиләдә иң абруйлы кеше булды. Аңлашыла инде, бала чакта безнең проблемалар белән вакытвакыт кына шөгыльләнергә мөмкинлек тапты. Әммә алар төп, стратегик проблемалар иде.

Минем өчен Луизадан да кадерлерәк хатын-кыз юк. Бу тормышта нәрсәгә булса да ирешә алганмын икән, күп очракта аңа бурычлымын. Шунысы кызганыч: гаилә өчен вакыт кына җитеп бетми. Көнозын эштә булам, гадәттә кичләр дә, ял көннәре дә буш түгел. Кайчагында нәрсә булса да килеп чыгып, әллә кайчан планлаштырылган чаралардан да баш тартырга туры килә. Әммә хатынымы һәм, гомумән, өйдәгеләргә бик рәхмәтлемен: алар минем гел мәшгуль булуымны аңлап, шуңа риза булып яшиләр.

Улыбыз тугач, алдыбызга сорау килеп басты. Югары уку йортында читтән торып кемгә укырга: Луизагамы, миңамы? Икебез дә укысак, гаилә мәшәкатьләрен тартып булмаслыгы көн кебек ачык. Шулвакыт техникум тәмамлаганнан соң институтка керергә җыенган Луиза: «Син укы. Сиңа кирәгрәк», – диде... Балаларны тәрбияләгәне, өйдә җылылык тудырганы, мөмкинлекләремне тормышка ашырырга ярдәм иткәне өчен мин хатыныма бик рәхмәтлемен. Әммә аның алдында хәзер дә үземне гаепле сизеп йөрим.

Луиза МӨХӘММӘТШИНА, хатыны:

Комсомол оешмасының бүләкләр тапшыруга багышланган тантанасында чәчен кыска гына итеп кистергән, ыспай гәүдәле, әле генә армия сафларыннан кайткан бер егеткә игътибар иттем. Бик күркәм кыяфәтле, үзе минем якка күз дә салгалап ала, тик бергә никтер чакырмый...

Танышканнан алып өйләнешкәнчегә кадәр шактый вакыт узды. Бу вакыт эчендә бер-беребезне белү генә түгел, әллә нича тапкыр упкәләшергә дә, хәтта аерылышырга да мөмкин иде. Әммә, ни гаҗәп, боларның берсе дә булмады. Хәтта Фәрит соңыннан: «Бу еллар әрәмгә киткән икән, баштан ук өйләнешәсе калган», – дигән сүзләр дә әйтте.

Дамир МӨХӘММӘТШИН, улы:

Мин мәктәптә укыганда, әй эшләрен эшләмәс өчен, гел тизрәк үсеп җиту турында хыялланa идем. Әтием бервакыт миңа: «Улым, әгәр син юләр булмасаң, гомерең буена укырга туры килер. Безнең тормышта егет кешегә житмеш төрле һөнәр да аз», – диде.

Автомобиль – әти өчен аерым бер тема. Әйтергә кирәк, велосипедны санамаганда, безнең иң беренче транспортыбыз бишекле «Днепр» мотоциклы булды. Сеңлем Лилияне дә бала тудыру йортыннан шуның белән алып кайткан идек бугай. Ә 1982 елда беренче машинабыз – «копейка» пәйда булгач, Әлмәттән Ригага чыгып киттек. Аннан Кара диңгезгә, Кабардыга бардык. Төннәрне юлларда, кырларда үткәрдек. Ул вакытлар өчен үзенә күрә бер батырлык иде мондый сәяхәтләр. Әммә әтинең үзенә дә, машинасына да ышанычы зур иде. Мин гел аның янында булдым. Ул: «Машина иркәләгәнне, чистартканны һәм майлаганны ярата», – дип, еш кабатлый иде.

Лилия АБАШЕВА (Мөхәммәтшина), кызы:

Әтием бәйрәм оештырырга ярата һәм бу аның ничектер бик җайлы килеп тә чыга иде. Бервакыт шулай олы кызым Мәскәүдән дус кызын алып кайтты. Әтием данлыклы 21 нче «Волга»сында аларны аэропорттан каршы алырга барган. Музей экспонатында (дус кызы шулай дип кабул иткән) утырып йөрүенә бик нык шатланган иде ул.

...Ничек вакыт тапкандыр, әтием фотога төшерү белән дә бик мавыкты. Без аларны бергәләп ясый идек. Рәсемнәрнең һәрберсен мин могҗиза кебек кабул иттем. Әтием миңа шулай итеп балачакның тылсымлы мизгелләрен бүләк итте.

Остаз

Әнәс ГЫЙМАТДИНОВ, «Татнефть» оешмасының элеккеге генераль директор урынбасары:

Фәрит белән мин очраклы гына таныштым. Безнең Миңнебайда нефть әзерләү буенча комплекс, ә аның составында электр ярдәмендә сусызландыручы корылма бар иде. Бервакыт шулай территория буйлап барам, бер төркем егет, бик мавыгып, катлаулы контроль-үлчәү приборы янында кайнаша. Арада погонсыз гына солдат киеме кигән берәү бигрәк тә аерылып тора. Бирелеп эшләве генә түгел, иптәшләре белән чын күңелдән, тыныч кына аралашу рәвеше дә сокланырлык иде. Күренеп тора: башкалар янында абруе зур моның. Шунда кемнәндер: «Бу нинди егет?» – дип сорадым. Фәрит Мөхәммәтшин, дип җавап бирделәр. Бу минутта аның исеме миңа берни дә әйтми иде әле.

...Сиксәненче еллар ахырында, Фәрит Хәйруллович Казанга киткәч, шәһәрдә башбаштаклык хакимлек итә башлады. Шәймиев килде. Ул 5–6 кешене кунакханәгә чакырды да: «Алга таба ничек яшибез? Шәһәрнең беренче кешесе итеп кемне сайлыйбыз?» – диде. Һәр кешедән аерым-аерым сорап чыкты. Мин дә башкалар кебек үк: «Мөхәммәтшинны кайтарырга кирәк. Ул монда барысын да җайга салыр», – дидем. Тиздән аны Әлмәткә беренче секретарь итеп кайтардылар.

Дуслар

Мөдәссир СӨЛӘЙМАНОВ, Әлмәт шәһәре спорт комитетының элеккеге рәисе:

Алтмышынчы еллар башында мин әле башлангычта гына укый идем. Күңел ачу өчен урыннар булмау сәбәпле, ишегалдындагы футбол кыры безне гел үзенә тартып торды. Шулай бервакыт дусларым белән уенны күзәтәм. Капкада Мөхәммәтшин тора, аны ишегалды компаниясендә үзара «Гарринча» дип йөртәләр иде – шундый күренекле Бразилия футболчысы бар иде бит. Әйтергә кирәк, Фәрит үзе дә аңа охшаган иде, уйнавы да һәвәскәр дәрәҗәсенә күрә капкачы буларак та, һөҗүм итүче буларак та матур, чын күңелдән булды.

...Күзгә-күз без аның белән 1965 елның җәендә очраштык. Бишенче сыйныфны тәмамлаган ел иде. Өйдә утырасы килми, танцыга барырга иртәрәк, дус малай белән әнгер-меңгер вакытта Ленин мәйданы тирәсендә йөрибез. Безне ике комсомол дружинасы активисты туктатты. Берсе – Фәрит Мөхәммәтшин. Комсомол шәһәр комитеты да янәшәдә генә иде. Шунда безгә кичке сәгать унда урамда сукбайлар кебек селкенеп йөрүнең ярамаган эш икәнен кисәтеп, әңгәмә үткәрделәр. Соңрак белгәнемчә, Фәрит Хәйруллович бик мөләем, йөзеннән елмаю китми торган кеше булып чыкты. Әммә ул вакытта бик таләпчән, кырыс йөзле булып кына истә калган. Еллар үтте, шактый гына бергә эшләргә туры килде. Мин аның янында башка бервакытта да «гаепле укучы» хәлендә калмаска тырыштым.

Кагыйдә

Фәрит МӨХӘММӘТШИН:

Мөхәммәтшиннар нәселендә шулай кабул ителгән: сиңа ышанычкүрсәтәләр икән, үлсәң үл, тик ышанычны акла! Мин гомерем буена шушы принциптан читкә тайпылмаска тырыштым.

Чорны сайлап алмыйлар. Бары тик ничек һәм кемнәр белән яшәргә икәнлеген генә сайларга була.

(«Фарид Мухаметшин. Виражи судьбы» китабыннан алынды)

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хөрмәтле Фәрит Хәйруллович!

Юбилеегыз уңаеннан бихисап котлауларга «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе дә кушыла. Сезнең әйләнә-тирәдәгеләргә, гаиләгезгә карата булган җылы, эчкерсез мөнәсәбәтегез сокландыра. Оста җитәкче, сәясәтче булу белән бергә бу яктан да сез һәркемгә үрнәк. Кайда гына, нинди генә вазыйфада эшләсәгез дә, хезмәтегезне республика, халкыбыз файдасына җиренә җиткереп, зур төгәллек белән башкарасыз, сезнең өчен вак-төякләр юк. Матбугатка, журналистлар хезмәтенә игътибарыгыз өчен рәхмәт!

Сезгә сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә иминлеге телибез! Туган көнегез котлы-мөбарәк булсын!

ТАРИХТА ЧАРЛАНГАН ШӘХЕС

Индус ТАҺИРОВ, академик:

Миңа Фәрит Мөхәммәтшин белән күп еллар бергә эшләү бәхете насыйп булды. Ул минем күз алдымда Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең ышанычлы көрәштәшенә, утны-суны кичкән, тарихта чарланган сәясәтчегә әверелде. Иманым камил, ул – милләтебез үсешенә, республикабызның суверенлыгына зур өлеш керткән шәхес.

Фәритнең сәяси университеты үткән гасырның һич кенә дә гади булмаган 90 нчы елларына туры килә. Аның Аллаһы Тәгалә биргән сәләте чын мәгънәсендә нәкъ шушы елларда ныклап ачылды. Республикабызның Югары Советы Рәисе буларак суверенлык Декларациябезне кабул итүдә, референдум үткәрүдә һәм Россия белән Татарстан арасында тарихи килешүләрне төзү, кабул итүгә кертккән өлеше иң зур бәягә лаек.

Аның Референдум үткәрүдәге сәяси батырлыгын җәмәгатьчелек телеэкраннар аша күреп торды. Мәгълүм ки, анда «Сез Татарстан Республикасының суверен дәүләт, халыкара субъект булуына, үзенең Россия белән, башка дәүләтләр белән мөнәсәбәтләрен тигез хокуклы договорлар аша төзергә кирәклегенә ризамы?» дигән сорау куелган иде. Россиянең Конституцион суды референдумны үткәрмәү турында карар кабул итте һәм шушы мәсьәлә Россиянең Югары Советы сессиясендә каралды. Мөхәммәтшин ул сессиядә бердәнбер җавап тотучы иде. Россия Югары судының рәисе Валерий Зорькин депутатларны: «Әгәр дә референдумдагы сорауга уңай җавап алынса, бу республиканың бәйсезлеген игълан итү өчен юридик норма булачак. Моны һәрбер юрист шулай дип санар һәм хаклы булыр», – дип кисәтеп куйды. Шунлыктан Фәрит Хәйрулла улына дистәләгән четерекле сораулар яуды. Ләкин ул аларга лаеклы җавап бирә алды, үзен батырларча тотты. Ә бит башкача булса, аны шунда ук кулга алулары мөмкин иде. Ул моны белә иде. Ләкин курыкмады.

Референдумның нәтиҗәләре билгеле. Аңа сайлаучыларның 61,4 проценты «әйе» дип җавап бирде. Бу нәтиҗәдә аның өлеше зурдан-зур.

Бу аның сынауларының соңгысы булмады. Алда илне ГКЧП фетнәсе көтә иде. Республика җитәкчелеген, аларның беренчеләре булган Мөхәммәтшинны аны яклап чыгуда гаепләделәр. Аны тикшерүгә багышланган Югары Совет сессиясе барышында республика депутатларының «Народовластие» төркеме аның, рәис урыннын торып, тиешле карарны залга чыгып тыңларга тиешлеген таләп итте. Ләкин депутатларның күпчелеге Фәрит Хәйрулла улын яклап чыкты. Бу, әлбәттә, аның сәяси батырлыгының һәм дипломатик осталыгының нәтиҗәсе иде. Күпләр аның көчле шәхес икәнлегенә янә инандылар.

Әлбәттә, аның эшчәнлеге турында күп язып булыр иде. Яздылар да. Мин дә яздым. Бу очракта аларга туктальп тормастан, Фәрит Хәйрулла улының һәрвакыт тиешле урында һәм тиешле вакытта булуын ассызыклап, сүземне тәмамлыйм. Зур юбилее белән котлап, аңа исәнлек-саулык һәм яңа уңышларга ирешүен телән калам.

«УЛ – КҮҢЕЛЕ БЕЛӘН ДӘ ВОЛЕЙБОЛЧЫ»

Мансур КӘРИМОВ, Татарстан Волейбол федерациясенең башкарма директоры:

Спорт сөючеләр хәтерлидер: заманында Фәрит Мөхәммәтшин җиде ел Хоккей федерациясен җитәкләде. Ул чорда «Ак барс» тәүге мәртәбә Россия чемпионы булып танылды. 2011 елда аның Волейбол федерациясенә килүе безнең өчен мөһим вакыйга булды. Әлбәттә, федерация эшенә аны җитәкләгән кешенең абруе йогынты ясый. Зуррак максатлар куярга мөмкин, кем әйтмешли, ишекләр дә җиңелрәк ачыла. Әммә иң мөһиме: Фәрит Хәйруллович волейболны бик ярата. Ул – күңеле белән дә волейболчы. Әлеге спорт төренең соңгы еллардагы үсеше анә шуңа да бәйле.

Читтән караганда, айсбергның өске өлеше генә. Гади генә ярышны оештыру да күпме көч таләп итә! Фәрит Хәйруллович волейболны демократик, халыкчан спорт төре дип атый. Чыннан да шулай. Җәен – комлыкта, кышын кара урында уйнарга мөмкин. Чыгымнары да зур түгел. Бик динамикалы спорт төре. Балалар да, яшьләр дә, өлкәннәр дә уйный.

Татарстанда бик яхшы чыгыш ясаучы профессионал командаларыбыз бар. Ә безнең максат – волейболны массакүләм спорт итеп, халыкны сәламәт яшәү рәвешенә җәлеп итү. Уннан артык юнәлештә эшлибез. Ярышлар сабы бик артты. Студентлар лигасы барлыкка килде. Элек ул футбол һәм хоккейда гына бар иде. Аннары федерация президенты кубогы өчен сәнәгать оешмалары һәм авыл районнары ярыша башлады. Дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр катнашында турнирлар уза. Фәрит Хәйруллович бу вакыйгаларның барысы белән дә якыннан кызыксынып, җентекләп күзәтеп бара. Аның җитәкчелегендә оешкан мәктәп волейбол лигасы исә безнең төп проектларның берсенә әверелде. Безгә карап, мондый ярышларны илнең башка төбәкләрендә дә оештыралар.

«ҮСКӘЧ, ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН БУЛАСЫМ КИЛӘ»

Нина ШИМИНА, Татарстан Дәүләт Советы каршындагы Яшьләр парламенты рәисе:

Әле дә хәтеремдә: Фәрит Мөхәммәтшинны тәүге тапкыр моннан бик күп еллар элек яшьләр Иҗтимагый палатасы утырышында күрдем. Һәр чыгыш ясаучыны игътибар белән тыңлап, искәрмәләр ясап утырды ул. Һәркемгә исеме белән дәшеп, берәүне дә игътибарсыз калдырмады. Бернинди ясалмалык юк иде аның юмор катыш әйткән сүз-фикерләрендә. Залда аңа сокланмаган кеше калмады. Ник дигәндә, энциклопедик белемгә ия. Республика тормышыннан теләсә нинди тематикага тулы килердәй хатирәләр, искиткеч төгәллек белән китерелгән цитаталар, күпләр кызыгырлык эрудиция, бер ялгышмыйча әйтелгән саннар... Барысын да ничек исендә тота ала икән ул? Без шуңа аптырадык. Шунда мин янәшәмдә утырган иптәшемә шаярып кына: «Үскәч, Фәрит Мөхәммәтшин буласым килә», – дидем.

Күп еллар узгач, мине Яшьләр парламенты рәисе итеп сайладылар. Ә Фәрит Хәйрулла улы миңа үгет-нәсихәтләрен биргән беренче кеше булды. Яшьләр парламенты исеменнән теләк-тәкъдимнәребезне аңа юллап, «Мин каршы түгел. Ничек ярдәм итә алам?» – дигән җавап алганда, мин әле дә җылы хисләр кичерәм, үземнең ялгыз булмавымны тоям.

Мин аннан зирәклеккә өйрәнәм. Дәүләт Советының һәр утырышы – минем өчен зур дәрес. Фәрит Хәйрулла улының һәрнәрсәне һәм һәркемне җайлап, сөйләшүне иплән кенә кирәкле юнәлешкә җибәрә белүенә, хәтта иң җитди кунаклар белән дә вакыт кысасын чыкмавына сокланам. Сокланам һәм үзем дә шушы сыйфатларга ия булырга телим.

«БЕЗГӘ ЯБЫК ИШЕК ШАКЫРГА ТУРЫ КИЛМӘДЕ»

Маринэ ХУХУНАШВИЛИ, Казандагы күпмилләтле якшәмбе мәктәбенең директоры:

Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе 1995 елдан бирле эшли. Фәрит Мөхәммәтшин безнең тормышта 2007 елда пәйда булды. Шушы елны, зурлап, икенче корылтай уздырылды. Мин шунда чыгыш ясадым. Президиумда Фәрит Мөхәммәтшин, Минтимер Шәймиев артында утырдым. Минем өчен горурлык иде бу. Татарстан халыклары ассамблеясы төзелеп, аның рәисе итеп Фәрит Мөхәммәтшин билгеләнгәч, оешманың дәрәҗәсе артты. Безгә мөнәсәбәт тә үзгәрде. Халыклар дуслыгы йортының иске бинасына Фәрит Мөхәммәтшин еш килә иде. Аннан аны төзекләндерә башладылар. Гадәттә, безгә җитәкчеләр буй җитмәслек кебек тоела. Фәрит Мөхәммәтшин менә шушы чикләрне бетерде, чөнки без аңа төрле сораулар буенча мөрәҗәгать итә алдык. Бу – бик зур нәрсә. Якшәмбе мәктәбенә килгәндә, Фәрит Хәйруллович укү йортының абруен күтәрде. Еллар үткән саен, аның мәктәпнең үсеше белән кызыксынуы торуы безгә җавапылык өсти.

2014 елда Туган телләрне, дәүләт һәм башка телләрне саклау буенча дәүләт программасы эшләнде. Без шуңа төркемдә катнаштык. Башка халыкларның телләрен өйрәнү һәм саклау юнәлеше буенча эшләдек. Үз бурычлыбызны белеп, һәрберебез үзебезгә мөһим булган программаларны кертергә тырыштык. Мин якшәмбе мәктәбенең фестивален, слетын, милли лагерьны һәм башка чараларны тәкъдим иттем. Тәкъдимнәребез төрле каршылыкларга очрады. Бу проблемаланы ничек тә булса хәл итәргә кирәк иде. Фәрит Мөхәммәтшинга, хәлебезне аңлатып, хат яздым. Шуннан соң әлеге мәсьәләне Мәгариф һәм фән министрлыгы белән бергәләп хәл иттек. Бу да – аның тырышлыгы. Хәзерге вакытта ел саен 200дән артык бала лагерьда булый ал итә. Слет та – бик кызыклы формат.

Фәрит Мөхәммәтшинга нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәк тә, һәрвакыт ярдәм итте. Ни өчен якшәмбе мәктәбе озак еллардан бирле эшлиме? Безгә бервакытта да ябык ишекне кагарга туры килмәде. Республика җитәкчелеге туган телләрне, мәдәни мирасны саклауга игътибар бирә. Фәрит Мөхәммәтшинның башка телләрне кайгыртуын читтән күзәтү кызык. Туган тел аның өчен – нинди дер бер формула. Татарлар туган телен бәяли белә һәм бу башка милләтләрнең телләрен мөһимлеген аңлауда да чагыла.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Талашу

Талашуның сәбәпләре төрлечә була торгандыр инде ул. Ләкин күп вакытта бер дә юктан гына чыга. Ир белән хатын арасында бигрәк тә. Икесенең дә кәефсез чагы туры киләме инде шунда, хисләре үткен мизгелме… Хатыны бер сүз әйтә, ире җавап кайтара… Сүз арты сүз китә… Берсе туктагып торса я ишетми калса да алай булмас иде. Юк, ишетәләр. Андый чакта тавыш та көр була бит әле ул. Ишету сәләте дә көчле була. Хәтта әйтмәгән сүзне дә ишетергә мөмкинсең.

Әлеге вакыйга да шулай бер дә юктан гына килеп чыга инде. Моны миңа бер күршем сөйләгән иде. Хәтернең бер бүлмәсенә бикләп тордым да беркадәр вакытка онытты. Әле менә искә төште. Могҗиза икән бит. Хәтта талаш-гаугалар да бер дә юктан гына булмый икән. Алар да әллә нәрсәләргә сәләтле икән. Шуңа сезнең белән дә бүлешергә уйладым.

Яңарак кына өйләнешкән ир белән хатын шәһәр читендәге дачаларына барып, матур гына ял итәргә булалар. Табын әзерлиләр, мунча ягалар. Дусларын-фәлән-нәрен чакырып тормыйлар инде, икенче көнне хатынга эшкә китәргә кирәк, ул стюардесса булып эшли, бер минутка да соңга калырга ярамый. Яңа өйләнешкән парларның үзләренә генә дә оҗмах бит инде ул, артык кеше мөһим түгел.

Яратышып өйләнешкән кешеләр инде болар. Тормышта да бер-берсе өчен өзелеп торалар. Кода-кодагыйлар да тату яши. «Синең ата-иноң, минем әти-әни…» дип тарткалашыр сәбәпләре юк. Яшь хатын чибәр, акыллы, уңган, нинди генә эшкә алынса да, гөл иттереп куя. Аш-суга бигрәк маһир, пешергән ризыкын мактамый ашарлык түгел. Ир дә алтын куллы, юкка-барга кысыла торган бәндә түгел, сабыр холыклы. Гомумән, ачуланышырга берннди сәбәп тә юк.

Ләкин болар талашып китәләр. Һич югы ниндидер уртак эш эшләгәндә булса аңларга да мөмкин. Әйтик, бәрәңге утырткан вакытта. Ир казый, хатын бәрәнге сала. Һәм кузәнәкләрне тигезләп каплатып салып бару ниятеннән гел көрәк өстенә каплана. Ир бер кисәтә, ике… Һәм сабырлыгы сынып, кычкырып җибәрә. Яки анная да ямангарагы, туфрак каты булып, көрәге кинәт ычкынып китә дә кузәнәк салырга иелгән хатынның башына килеп бәрелә. Хатын җан ачуы белән кычкыра. Ир, күпме кисәттем бит, колагыңа да элмисең, дип кызып китә… Шул рәвешлерәк тавыш чыгарга мөмкин. Әле анысы да котыртучы шайтанның уң аягыннан торган көндә генә.

Ә бу икәү… мунча кергән чакта талаша башлый. Яңа гына өйләнешкән парларның мунчада талашып ятуын берничек тә күз алдына китереп булмый кебек. Зифа буйлы яшь чибәр хатын… Таза гәүдәле сокланггыч ирегет… Мунчада… Яратышып өйләнешкән шундый парның мунчада талашып ятуы үзе үк бер могҗиза кебек тоела. Ләукәгә салып, кычкырта-кычкырта каен пиннеге белән рәхәтләндереп чап бит инде, алсуланып ялтырап калырлык итеп аркасын ю… Шегыль беткәнмени мунчада бер-берсен яраткан ир белән хатынга?

Тик болар алай итмиләр. Тавышның нилектән чыккалыны да билгеле түгел хәтта. Соңыннан бу гауганың сәбәбен ир дә, хатын да берничек тә искә төшерә алмаганнар. Пыр тузып талашалар да шулай, кызуның чигенә җитәләр. Котырынган ир киемнәрен эләктереп чыга да хатынының өстеннән бикләп кайтып китә. Дача йортыннан документларын алып кына чыга да машинасын кабыза. Һәм шәһәрдәге фатирына элдерә. Ачуланышкан чакта Ходай кешенең һушын ала икән, диләр бит, дөрестер инде. Мунчада калган хатыны турында исенә дә керәп карамый моның.

Ә хатын мунча ишеген бәргәли. Ләкин иренең куллары алтын булгач, ишек кымшанып та карамый инде. Антырагач, кычкырырга тотына. Ишетүче булмыймы, ишетмәгәнгә салышаларммы – берсен дә ярдәмгә килми. Ярый әле җәй, көннәрнең җылы чагы. Хатын мунча алдындагы агач караватка урын җәеп ятып йоклый. Талашу да арыта торгандыр инде ул. Нәвем базарына тиз китә хатын. Тыныч йоклый. Иртән генә сикереп тора. Башта үзенең кайда икәнен, аннан соң нигә монда килеп йоклаганын аңлый алмый аптырый. Нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй тирә-ягына каранып ала. Мунча алдындагы сәгать унбер тулып ун минут киткән. Шайтан алгыры! Аңа бит эшкә китәргә кирәк иде! Хатын ишеккә ташлана, ә ул бикле.

Ул арада ире килеп җитә. Ул фатирына кайткан да ауган икән. Йокысыннан тору белән монда җилдергән. Сөйләшүе дә, үз-үзен тотышы да мулла писе кебек. Хатын инде эшенә өлгерүдән тәмам өметен өзгән. Иртәнге җиддәдә үк анда булырга тиеш иде. Кәефе төшкән. Үзенең дә гаебе бар кебек, кичә иренә әллә нәрсәләр әйтеп бетерде бугай. Бүген аны тиргәргә сәбәбе булса да, авыз ачып авыр сүз әйтерлек теләге юк. Ире дә гафу үтенә. «Ни өчен талаштык соң без? Нәрсәдән чыкты соң тавыш?» – дип икесе дә аптырашалар. Аралары арулана да, икесенең дә күңелендә кичәге хәлләр өчен үкену бар. Икесе дә үзен гаепле саный. Шул килеш кайтырга чыгалар. Бер сүзсез кайтудан ялкып, ире радиоалгычны куя. Радио хәбәрләре дә кызык түгел, бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга… Безнең футбол командасы тагын җиңелеп кайткан… Кайдадыр автобус авариягә очраган… Ниндидер самолет һәлакәткә юлыккан… Ир инде радионы сүндерергә дип үрелгәндә, хатыны кычкырып җибәрә:

– Тукта! – Һәм ул газаплы пышылдауга күчә. – Бу бит – безнең самолет. Мин бүген шунда очарга тиеш идем. Ә ул… һәлакәткә очраган…

Марат КӘБИРОВ

НИЧЕК ИНДЕ ҮЗЕМ ГЕНӘ?

Безнең заман герое

Республикада быел 11 нче сыйныф укучылары арасында татар теленнән сынауны нибары бер генә укучы сайлаган. Бу хакта без Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан белештек. Бердәнбер дигәнебез – Әдилә Шәйхетдинова Балтач районының Норма мәктәбендә белем ала. Мәктәпне быел 16 меңнән артык укучы тәмамлауны исәпкә алсак, Әдилә бүгенге заманның герое була түгелме соң?

– Республикада татар теле сынавын үземнең генә бирүемне белгәч, башта каушап калдым. «Ничек инде үзем генә? Бирә алырмынмы?» дигән сораулар борчыды. Ләкин соңыннан бердәнбер укучы булуым белән горурлана башладым. Алла боерса, югары балларга бирермен дип уйлыйм, – ди Әдилә Шәйхетдинова. – Татар теленнән имтихан тапшырам дигәч, җиңел бит инде ул, нәрсәсенә әзерләнәсең, дип аптырыйлар миңа. Имтихан нинди генә булмасын, аны әзерләнмичә генә тапшырып булмый. Татар теле – җәмгыять, рус теле, математика кебек үк фән. Имтиханнары сортларга аермыйм. Әйтик, татар теленә әзерләнү өчен көнгә ике-өч сәгать вакытымны бүләм.

Әдилә – Кили авылы кызы. Татар теленә мәхәббәтне аңарда беренче укытучысы Рәйханә Хафизова уяткан. Аннары Норма урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Энҗе Әсәдуллина әлеге кызыксынуны тагын да арттырган.

– Энҗе Васыйл кызы – иң яраткан укытучым. Бик акыллы, тырыш, сабыр. Минем өчен – авторитет. Нәкъ менә ул мине татар телен яратырга өйрәтте. Укытучыларыма бик зур рәхмәтлемен, – ди Әдилә.

Әдиләгә китап җене дә кагылган. Элек төнгә кадәр укыса, хәзер имтиханнарга әзерләнгәч, вакыты аз кала. Тик атнага 2–3 китап укымыйча түзә алмый. Кечкенәдән шигырьләр яза.

– Китап уку мине тынычландыра, уйланырга мәҗбүр итә. Нәкъ менә аны кулга тотып уку бик ошый. Кызыгы, тәме шунда бит. Хәзерге яшьләрне бу шөгыль әллә ни кызыксындырмый. Әмма алар арасында электрон китап укучылар аз димәс идем. Күбрәк фантастика җанрын яраталар, – ди китапка гашыйк кыз.

Укытучысы Энҗе Әсәдуллина да укучысы белән горурлана. Горурланмаслык та түгел, 7 нче сыйныфтан бирле район, республика олимпиадаларында катнашып, призлы урыннарны алып килә, башка бик күп бәйгеләрдә дә көчен сыный. Әдилә бик эзләнүчән, нинди генә биремнәр тапмый да, нинди генә сораулар әзерләми. Кайбер сорауларга җавап бирү өчен, укытучысына да кайчак бик күп эзләнергә туры килә.

– Уку елы башында ук Әдиләм туган телдән Бердәм республика имтиханы тапшырасы килү теләген белдерде. «Нигә кыенсынып кына җиткерәсең бу теләгеңне? Синең бу имтиханны югары балларга бирү мөмкинлегең зур бит, татар теле укытучысы булырга теләвең бары тик соклану хисләре генә уята, мин синең белән горурланам», – дидем, – ди Энҗе Әсәдуллина. – Ул – бик гади, эчкерсез кыз. Тәнкыйтьне дөрес кабул итә белә. Мин Әдиләдән киләчәктә менә дигән укытучы, үз телен, Ватанын, халкын яратучы ватанпәрвәр шәхес чыгар дип ышанам.

Энҗе Әсәдуллина укучыларында туган телгә, татар әдәбиятына караш бик уңай дип бәяли. «Балалар бездә саф татарча сөйләшә, иҗат белән шөгыльләнә. Республика, район җитәкчелеге тарафыннан да, балаларның сәләтен үстерү өчен, барлык мөмкинлекләр тудырыла, олимпиада, төрле бәйгеләрдә катнашып, күпме призлар, югары уку йортларына керү өчен баллар да алырга мөмкин. Киләчәктә дә татар теле һәм әдәбияты укытучыга игътибар кимемәсен дигән теләктә калам. Шушы дәресләрдә без укучыларда телебезгә, халкыбызның тарихына, гореф-гадәтләренә, гаилә традицияләренә ихтирам, ярату хисләре тәрбиялибез бит», – ди мөгаллимә.

Әдиләнең КФУда татар теле һәм әдәбият, рус теле укытучысы белгечлеге буенча белем аласы килә. Татар теле имтиханы исә укырга керер өчен кирәк.

– Татар телен бик яхшы беләм. Татар теле һәм әдәбиятыннан узган бәйгеләрдә уңыш еш елмая. Быел КФУ үткәргән мәктәп укучылары олимпиадасында призлы урын яуладым. Бу олимпиада укырга кергәндә балл өсти. Кызганыч, калганнары андый мөмкинлек бирми. БДИ – зур сынау. Курку хисе бар, әлбәттә. Әмма мин һәрвакыт яхшыга өметләнәм. Укып бетергәч, татар теленә өстенлек бирәчәкмен, чөнки ул – минем туган телем, аны тагын да тирәнрәк өйрәнәсем килә, – ди Әдилә.

Сүзебез җитди темаларга борыла. «Хәзерге вакытта балаларга туган телне өйрәнү кызык түгел. Шуңа күрә яңа төрле ысуллар уйларга кирәк. Бәлки уеннар аша өйрәтермен. Әлбәттә, ул иске түгел, яңа форма булачак», – ди кыз.

Кызык, туган телне саклау турында ниләр уйлый икән ул? Әдилә әйтүенчә, хәзерге вакытта туган телгә мөнәсәбәт һәр кешедә төрлечә. «Туган телне без сакларга тиеш. Элек-электән әби-бабаларыбыз аны әманәт итеп тапшырган, ә без бу телдә аралашуны киметәбез. Төрле олимпиадалар, конкурслар булып торса, туган телебез онытылмас. Хәзер мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбият дәресләре атнага берәр генә керә. Әлбәттә, бу бик аз. Бер дәрестә генә күп әйбер үтеп булмый. Шуңа күрә, дәресләрнең санын арттырырга кирәк. Саф татар авылларында сабыйларның бер-берсе белән русча сөйләшүе дә күңелле түгел. Белмим, моның сәбәбе мультфильмнарның русча булуында гынамы икән? Хәзер татарчалары да бар бит. Милләтне юк итү өчен, телне һәм динне бетерү кирәк, дип әйткәнннәр. Милләтебезнең киләчәге – безнең кулда, – ди милли җанлы Балтач кызы.

Сәрия МИФТАХОВА

САН

Быел **9** нчы сыйныфлар арасында туган телдән имтиханны **1371** укучы тапшырган. Шуларның **1263**е – татар, **73**е – чуаш, **21**е – удмурт һәм **14** е мари телен сайлаган. Катнашучылар саны буенча Кукмара районы беренче урында санала. Анда **445** укучының **139** бу туган телдән имтихан тоткан. Балтач, Чүпрәле, Әлки, Актаныш, Әгерҗе, Сарман, Кайбыч, Әтнә, Саба районы укучыларын да үрнәк итеп китерергә була. Тик Апас, Буа, Югары Ослан, Алабуга, Кама Тамагы, Менделеевск, Спас, Чирмешән районнарында бер генә укучы да имтиханга туган телне сайламаган.

БАЛА ӘТИ-ӘНИСЕН КАБАТЛЫЙ

…Балалар барысы да гаилә корган. Алар икәүләп ял итәргә йөриләр, спорт белән шөгыльләнәләр. Өйдә көн саен тәм-том пешә, оныклар кунакка килә. Кукмара районының Вахит авылында яшәүче Айгөл Сәмигуллина олыгайган көннәрен әнә шулай күз алдына китерә. Күпләр кызыгырлык картлык бу. Хәер, аларның яшьлекләре дә башкаларга үрнәк итеп куярлык.

– Райнурны мин кечкенәдән беләм. Бервакыт тракторына утырып, безнең авылга печән чабарга килгән иде. Чәй эчәргә керде. Шунда танышттык, – дип искә ала Айгөл. – Ул вакытта миңа – 12, Райнурга 15 яшь иде. Дуслашып киттек. «Мәктәпне бетергәч, кияүгә бирәм. Кирәк булса, ирен укытыр әле», – дип, әти еш кабатлый иде. Фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килгән, күрәсең. Райнур әтиәнисе белән киңәшләшкәч, мин аларның гаиләсенә килен булып төштем. Каенатам Зиннур белән каенанам Кадриянең бишенче баласына әверелдем. Үз кызларыдай каршы алдылар. Яшьлек белән ирем гаиләсенә бик тиз ияләндем. Тәрбиям шулай иде. Барган җирдә таш буласың! Кеше көнләшерлек булсын дип яшәдем. Эштән куркып тормадым. Әтиәни белән дә матур яшәдек. Безнең өчен алар үрнәк булды.

Сәмигуллиннар биш бала тәрбияли. Һәр сабый үз ризыгы белән туа, ди алар. Олы улары Динисламга – 11, Сөләйманга – 10, Гайшәгә – 8, Әхмәткә – 6, Мәрьямгә – 3 яшь.

– Төп йортта алты ел яшәдек. Балалар кечкенә чакта әби-бабайлы булу – бәхет ул. Әтиәниләр әле дә ярдәм итеп тора. Ирем колхозда эшләгәч, яшь белгечләр программасы буенча йорт салып чыктык. Ул вакытта өч балабыз бар иде, – ди Айгөл. – Аннары тагын икене алып кайттым. Кияүгә чыккада, мин ун бала дип хыялланa идем. Кем белә, Аллаһы Тәгалә бирсә, тагын табармын.

24 яшендә 5 бала әнисенә әверелгән Айгөл әйтүенчә, дәүләткә ышанып кына бала алып кайтмаган алар.

– Үзең тырышырга кирәк. Син бит балаларны үзең өчен, картлык көнеңдә ярдәмчеләрең булсын дип табасың. Шуңа да матур, мул тормышта яшисең килсә, тырышасың инде. Эштән куркып ятмыйсың, – ди Айгөл.

Үзенең белмәгән эше юк. Бәйли дә, тегә дә, заказга тортлар да пешерә икән әле. Элек күп итеп мал тотканнар. Бүген абзарларында 60тан артык сарык бар.

– Авылда бишәр сыер асраучы бар. Ә менә сарык малы күп түгел. Сорап килүчеләр шактый. Күбрәк корбанлык өчен үстерәбез. Коронавирустан сихәтләнеп, нәзер корбаны чалдыручылар да күп. Бала туган саен, гакыйка корбаны өчен дә заказ бирәләр. Гел сарык ите генә ашап торучылар да бар, – ди ул.

Айгөлнең шәһәргә китү теләге беркайчан да булмаган. Кунакка баргач та, арып кайтам, ди ул. Вахитлары яратмаслык та түгел шул! Шәһәрдәге кебек яшиләр. Кичләрен балалар белән паркка чыгалар. Урамнарында – асфальт юл. Кибетләре җитәрлек, мәктәбе, бакчасы бар. Кыскасы, Айгөл тормышына шөкер итеп, тормышның ямен белеп яши. Авыр чаклары да була Сәмигуллиннарның. Ике ел элек олы уларында шикәр авыруы табыла. Бер атна ут эчендә яшиләр. Уйламаган уйлары калмый.

– Әле ярый бу авыру гына булган дип, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйттек. Дөньяда әллә нинди авырулар бар бит. Дөрес итеп туклансаң, вакытында даруларын эчсәң, шикәр чиренә түзәрлек, дидек. Безнең әйдә бер әби шушы авыру белән бик озак яшәде. Без дә яхшыга өметләнәбез. Гаиләбезгә килгән бер сынау инде бу, – ди Айгөл.

Ничек итеп гаиләне сакларга соң? Биш балага тәрбия бирү дә җиңел түгел. Айгөлдән әнә шул хакта сораштык.

– Гаиләдә һәр чорның үз мәшәкате була. Балалар кечкенә вакытта бер төрле, үсә башлагач, башка проблемалар килеп чыга. Әмма тормыштагы хәлләрне кабул итеп, сабак алырга, җаен табарга кирәк. Гаилә тормышында иң мөһиме – сабырлык, – ди ул. – Безнең өйдә ир сүзе – закон. Райнурның күңеле киң аның. Ул беркайчан да авырлык китерми, тынлый, теләкләремә каршы килми. Безнең мөнәсәбәтләрне балалар күреп тора бит. Аларны тәрбиялисе дә юк. Әти-әни ничек яши, алар шулай эшләячәк. Гаиләне ир дә, хатын да сакларга тиеш. Ул бит – икең төзегән дәүләт! Уйлап эшләргә, уйлап сөйләргә, иң мөһиме – киңәшләшергә кирәк. Кайчак үлеп ярату да кирәкми. Бер-береңне хөрмәт итсәң, шул җитә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 270

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерен басыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+